## ОНЫТМАСКА, ОНЫТТЫРМАСКА!

**Киләсе елдан мәктәпләрдә бердәм тарих дәреслекләре кертергә җыеналар**

> 2

## БӨРТЕК КАДЕРЕ

**Фермерлар чаң суга: амбар тулы ашлыкны кая куярга?**

> 2

## КАЛӘМ КӨЧЕ

**105 еллык бәйрәмебез уңаеннан баш мөхәррир уйланулары**

> 5

## КЫЗЛАР ЧОРЫ

**Бу вакыт газетабызның матур бер сәхифәсе булып тарихка кереп калыр**

> 6


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 34 (29001) | Шимбә | 11 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# БАЛАГА КАЕШ КИРӘК!

**Татарстан юлларында фаҗигаләр артса да, һәлак булучылар кимегән. 424 юл һәлакәтендә 39 кешенең гомере өзелгән, 559ы имгәнгән. Аның каравы балаларга куркыныч яный. Алар катнашындагы аварияләр дә, имгәнүчеләр дә, корбаннар да арткан. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Татарстан буенча Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов журналистлар белән очрашуда ата-аналар җаваплылыгы турында сөйләде. Бала йөргән юлны алар да белергә тиеш.**

### Кулда булса, чыгып оча

Быелның ике аенда республика юлларында балалар катнашында 44 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 3 сабыйның гомере өзелгән, тагын 49ы имгәнгән. Куркыныч саннарның өчесе дә узган елгыдан күбрәк. Фаҗигале очраклар еш кына ата-ананың игътибарсызлыгы аркасында килеп чыга. Әйтик, шул ук махсус утыргычны иминлек түгел, ә инспекторлар штраф язмасын өчен йөртүчеләр дә җитәрлек. Күпсанлы тикшеренүләр исә андый утыргычның үлем-китем очракларын – 54 процентка, имгәнү ихтималын 76 процентка киметүен раслаган.

– Кечкенә сабыйлар да машинада барганда махсус утыргычта булырга тиеш.

Быелның ике аенда Татарстанда 424 юл һәлакәте килеп чыккан. Аларда 39 кешенең гомере өзелгән, 559ы имгәнгән. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, республикада юл фаҗигаләре саны да (3,4 процентка), аларда имгәнүчеләр саны да (6,5 процентка) арткан. Үлүчеләр саны кимегән (13,3 процентка).

Юл фаҗигасенә китергән иң төп сәбәпләр:
- каршы полосага чыгу (55,6 процент);
- җәяүлене бәрдерү (28,3 процент);
- каршылыкка килеп бәрелү (5,1 процент);
- туктап торган транспортка бәрелү (3,3 процент).

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ата-аналар шуны истән чыгармасын иде: авария килеп чыккан очракта, кулдагы баланы тотып калып булмый яки сез аны үзегез изәчәксез, – дип кисәтте Рөстәм Гарипов журналистлар белән очрашуда.

Юлдагы хәлләр дә бу сүзләрнең хаклыгын раслап кына тора. Әйтик, күптән түгел генә Бөгелмәдә җитди юл һәлакәте килеп чыккан һәм анда махсус утыргычтагы сабый гына исән калган.

### Үзең барып карыйсы

Балагыз белән өйдән мәктәпкә кадәр җәяү барып, аның йөргән юлын тикшерегез! Рөстәм Гарипов ата-аналарга шундый киңәш бирде.

– Балагыз белән аның мәктәпкә яки башка урыннарга йөри торган юлларыннан җәяү барып, андагы куркыныч җирләрне тикшерегез. Алар турында шундук безгә хәбәр итегез, – ди Татарстанның баш дәүләт инспекторы.

Быел республикада җәяүле балалар катнашында 17 юл һәлакәте килеп чыккан. 1 баланың гомере өзелгән, 19ы имгәнгән.

– Чаллыда рөхсәт ителмәгән урында юл аша йөгереп чыккан баланы машина бәрдергән. Кызганыч, аның гомере хастаханәдә өзелде. Шуңа күрә тагын бер кабатларга туры килә: балаларыбызның йөргән юлларын яхшылап өйрәнергә кирәк. Мәктәпкә, спорт яки күңел ачу биналарына кайсы юлдан бара, кайсыннан кайта? Яңа гына телгә алган аяныч очракта баланың бассейнга баруы булган. Берничә метр ераклыкта гына җәяүле кичүе урнашуга карамастан, юлны тиешсез урында йөгереп чыгарга уйлаган ул, – ди Рөстәм Гарипов.

Кагыйдәне балалар бозса да, ахыр чиктә, барыбер ата-аналар гаепле. Димәк, өйрәтмәгән, аңлатмаган, кисәтмәгән. Үзе дә каешын эләктермәгән, кешегә юл бирмәгән, кызыл утка туктамаган, юл аша чыкканда телефоныннан аерыла алмаган.

Белгечләр баланың киемендә яктылык кайтаргыч элементлар булырга тиешлеген дә искәртә. Финляндиядә, әйтик, моны закон белән мәҗбүр итәләр. Андый тәртип гамәлгә кергәч, җәяүле балалар катнашындагы юл һәлакәтләре саны 75 процентка кимегән. Рөстәм Гарипов фикеренчә, белем бирү оешмалары тирәсендәге җәяүле кичүләре янына өстәмә яктырткычлар да куярга кирәк.

### Җиде кат уйла

Белгечләр баланың туган көненә мопед, мотоцикл ише кәттә бүләк ясар алдыннан да җиде кат уйларга киңәш итә. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының өстәмә белем бирү бүлеге җитәкчесе Айгөл Кашапова Алабугада килеп чыккан фаҗигане искә алды.

– Узган елның 24 маенда Алабугада 14 яшьлек баланың гомере өзелде. Әтиәнисе аңа туган көненә мотоцикл бүләк иткән һәм шушы «бүләк» аркасында баланы туган көнендә җирләргә үк туры килде. Аның йөртү таныклыгы да булмаган, билгеле. Шуңа күрә ата-аналар баласына мондый куркыныч бүләк ясар алдыннан шуны истә тотсын иде: баланың йөртү таныклыгы, махсус киеме булырга, ул юл йөрү кагыйдәләрен белергә тиеш, – диде министрлык вәкиле.

## Истәлек баганасы ачыла

Башкалабызның Төньяк вокзалы янындагы скверда «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» стеласы төзелеп килә. Аны 8 майда ачу күздә тотыла.

Стеланың биеклеге – 26 метр (8 катлы йорт биеклегендә). Ике ягында пилоннар (терәү баганалары) урнаштырылачак. Истәлек композициясе проектын скульптор-монументалист Данис Стритович эшләгән. Стеланың өске өлешендә Казан гербы сурәтләнәчәк, ә астында шәһәргә мактаулы исем бирү турында Россия Президенты Указы белән табличка урнаштырылачак. Бер пилонда – рус һәм татар телләрендә «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» дигән язулар, икенчесендә Татарстан башкаласында яшәүчеләрнең хезмәт батырлыгын (кырларда, станоклар, госпитальләрдә эшләүчеләр) сурәтләгән барельефлар булачак. Композиция утлар белән яктыртылачак.

Исегезгә төшерәбез: «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» дигән мактаулы исем башкалабызга 2020 елда бирелде. Ул вакытта тагын 19 шәһәр шундый исемгә лаек булды. Аларның һәркайсында шәһәр гербы һәм мактаулы исем бирү турында Россия Президенты Указы белән стела куелачак.

Узган ел Төньяк вокзал янындагы скверда «Хәтер бакчасы» акциясе уздырылуын да искәртеп үтик. Шул чагында шәһәрдә яшәүчеләр Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән бергә 30 агач утыртты.

## *Табиб киңәше комачауламас*

Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин табибларга хатын-кызларны аборт ясатмаска үгетләргә кушты. Бу хакта ул Чаллының сәламәтлек саклау тармагы утырышында әйтте. «Сездә үлем-китем күрсәткече – республикада иң түбәннәрдән берсе. Икенче яктан, сездә туучылар саны кими. Ә бер елда күпме аборт ясала? Бу хакта кемдер нәрсә дә булса әйтә аламы? Юктыр, мөгаен? – диде министр. – Социаль проблема бу. Аңа медицина гына да йогынты ясамый әле. Хатын-кызлар консультацияләрендә үгетләү кабинетлары булырга тиештер. Хатын-кыз йөккә узып, ниндидер сәбәпләр аркасында ялгыз кала икән, без, һичшиксез, аны аборт ясатмаска күндерергә тиешбез».

Узган ел йомгаклары буенча Чаллыда үлем-китем күрсәткече 28,7 процентка кимегән: 1 мең кешегә 9,2 очрак туры килгән. Шул ук вакытта бала тудыру 1,4 процентка азаеп, 1 мең кешегә 9,3 очрак тәшкил иткән.

## Яз тәэсире

Яз башында Татарстанда кайбер ризыкларның бәясе төшкән. Аерым алганда, сыр һәм пешерелгән колбаса хакы кимегән.

Республикада 27 февральдән 6 мартка кадәрге чорда кыяр барыннан да күбрәк – 16,74 процентка арзанаеп, килосы 192,92 сумга калган. Бу яшелчәнең уртача бәясе инде 3 атна рәттән түбәнгә тәгәрәгән.

Татарстанстат мәгълүматларына караганда, бер атна эчендә пешерелгән колбаса хакы – 1,7 процентка (килосы 395,92 сумга кадәр), каты һәм ярым каты, йомшак сырлар – 1,47 процентка (килосы 630,18 сумга кадәр) төшкән. Токмачның уртача бәясе 1,13 процентка кимегән (килосы 69,67 сум). Шулай ук тоз, югары сортлы бодай оныннан токмач, сосиска һәм сарделька бәясе төшкән. Тавык ите, атланмай һәм үсемлек мае, арыш, арыш-бодай икмәге, тары ярмасы, карабодай да берникадәр арзанайган.

pixabay.com

## *Ышанычлы булыр*

Интернет-кибетләргә сатучыларның эшенә күз-колак булуны, үз мәйданчыкларына үтеп кергән товарларының чынлыгын тикшерү бурычын йөкләячәкләр. «Известия» язганча, бу мәсьәлә Роспотребнадзор каршындагы иҗтимагый советта карала.

Белгечләр әйтүенчә, маркетплейслардагы товарлар «Честный знак» дигән маркировка системасы ярдәмендә тикшерелергә мөмкин. Анда сатучылар, шулай ук маркировкалы (димәк, ялган түгел) товарлар турында да барлык мәгълүматны табарга мөмкин. Тик бу аяк киеме, хушбуй, су һәм башка шундый товарларга гына карый әле.

Онлайн кибетләр әлегәчә үзләрен товар белән тәэмин итүчеләрне тулысынча контрольдә тота алмый. Шуңа күрә кулланучыларга ялган товар эләгү куркынычы бар.

Һава торышы

# Тагын ун көн көтәсе

**Яз, беренче ае килүгә үк, җиң сызганып эшкә кереште. Урамда җылы, аяк астында – су, өй кыекларыннан көндез генә түгел, төнлә дә тамчы тама. Иртә язмы бу? Әнә шул сорауга җавап эзләдек.**

КФУның Метеорология кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев сүзләренә караганда, март өчен гадәти булмаган җылы һава торышы безгә Атлантикадан килгән.

– Һава температурасы картасына карасаң, көньякта – җылы, төньякта – салкын, яз башына хас булган салкын «тап»лар юк, – ди белгеч. – Якын арада һава торышы кискен үзгәрергә охшамаган. Салкыннар бер дә булмаячак, дигән сүз түгел, әлбәттә. Без якын киләчәкне генә фаразлый алабыз. Әлеге күзәтүләрдән чыгып, шуны әйтә алам: март гадәттәгедән җылы булачак. Ай башы тиешле нормадан 2,5 градуска югарырак булды. Мартның икенче ункөнлеге дә 4 градуска җылырак булачак дип көтелә. Татарстанда кар катламының биеклеге нормадан 10 сантиметрга биегрәк. Шунысы кызык: гыйнвар – февральдә явым-төшемнәр гадәттәгедән азрак теркәлде, ә җир өстендәге ак тун – ноябрь, декабрь карлары. Мондый язның тискәре, әмма котылгысыз яклары да бар. Һава торышы көндез җылы, төнлә салкын булганда, юллар ныграк туза. Йорт түбәләрендә боз сөңгеләре дә тизрәк үсә. Шуңа күрә коммуналь хезмәткәрләргә кичекмәстән йорт түбәләрен кардан чистарту эшенә керешергә кирәк.

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев, чын яз атна-ун көннән башланачак, ди.

– Былтыр кара каргалар 19 февральдә килгән иде инде. Быел язның беренче кошлары 5 мартта күренде. Яз вакытлы гына килә. Хәтерләсәгез, былтыр февральдә – март, мартта февраль булды. Апрель һава торышы календарьдагы 30 көн урынына, 40 көн буе дәвам итте. Чәчүгә дә май бәйрәмнәре алдыннан гына чыктылар. Май кыска гына булды да, июнь башында тагын суытып җибәрде. Үләннәр дә үсә алмады. Шуннан кисәк кенә җылытты. Яз иртә килде, тик табигать барыбер үз җаена кайтты. Быел февраль чагыштырмача җылырак килде. Әшәке бураннар да булмады. Чын яз 20 марттан соң башланачак, – ди халык синоптигы.

Ул быелгы җәйдән ни көтәргә икәнен дә фаразлады.

– Быел Раштуа суыклары булды, ә Кач ману суыклары булмады. Димәк, июнь ахыры – июль башында, ә бу – башак өлгерә торган вакыт, салкынча булачак дигән сүз. Шуңа күрә урып-җыю тоткарланырга мөмкин. Игътибар иткәнсездер, бу көннәрдә көндез һава торышы бик матур, иртә-кич кар ява. Димәк, урып-җыю вакытында да явым-төшемнәр булачак, эшнең озакка сузылуы ихтимал. Иртән яңгыр яугач, басуга тиз генә чыгып булмый бит. Быел кар яуды да, һава торышы җылытып җибәреп, карны ябыштырып куйды, җылытты да ябыштырды. Бөтен җирдә кар тигез. Югыйсә алдагы елларда бураннар карны авылларга китереп тутыра да, басулар ачык кала иде. Бер генә нәрсәдән шикләнәм: каты кар капламы астында уҗымнар сулый алмый. Көздән алар бик әйбәт иде, һава калмагач, үләргә мөмкиннәр, – ди Әмир Шәрәфиев.

Гидрометцентрдан алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда алга таба да хәзерге кебек һава торышы сакланачак. Төннәрен салкынча, явым-төшемнәр ихтимал, көндез исә 7 градуска кадәр җылы вәгъдә иткәннәр. Аяк астында – бозлавык. Шуңа күрә дә ЮХИДИ инспекторлары юлларда аеруча сак булырга киңәш итә.

Эльвира ВӘЛИЕВА

МАРТ АЕНА СЫНАМЫШЛАР
- Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.
- Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.
- Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.
- 14 март нинди – җәй шундый.

Сүзгә-сүз

**Иван СОВЕТНИКОВ, Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы (Рослесхоз) җитәкчесе:**

Узган елда урман янгыннары мәйданы 3 тапкыр: 10,1 млн гектардан 3,3 млн гектарга кадәр кимеде. Яңартылган урманнар күләме янгында зыян күргән мәйданнан 18 процентка артык. Урманнарны янгыннан саклау өчен 8,2 млрд сум акча бүлеп бирелде.

## ТАТАРСТАНДА – КРЕДИТ

**Илкүләм кредит бюросы мәгълүматларына караганда, 2023 елның беренче аенда бирелгән кулланучылар кредиты саны буенча Татарстан Россиянең 30 төбәге арасында бишенче урынны били.**

Мәскәү >> **52,1 мең** кредит

Мәскәү өлкәсе >> **45,7 мең** кредит

Краснодар крае >> **35,5 мең** кредит

Санкт-Петербург >> **33,1 мең** кредит

Татарстан >> **30,2 мең** кредит



## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

# *Кеше һәм вирус: кем кемне?*

Кеше затының хәтере кыска. Без ул чир хакында инде оныта да башладык. Онытуга, әлбәттә, бүгенге сәяси вазгыять тә күпмедер сәбәпчедер. Ни генә булмасын, ВОЗның (Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы) соңгы мәгълүматлары буенча, 690 миллион кешене чирләткән, 6,8 миллионының гомерен өзгән COVID-19 хакында хәзер еш искә алмыйлар.

Тик бүген хәтерне бераз яңартмый булмый. Шул зәхмәттән беренче кеше дөнья белән хушлашканга бүген төгәл 3 ел тулды. Нәкъ шул көнне – 2020 елның 11 мартында ВОЗ чирнең пандемия икәнен, ягъни дөньяви эпидемия төсмерен алуын да хәбәр итте. Шул датадан соң үк үлүчеләр саны геометрик прогрессия буенча арта башлады. Кешелек дөньясы куркуга калды. Элек хайваннар арасында гына йөргән таҗлы вирусның кайсыдыр бер мутациясенең кешегә күчкәнлеге, аның үтә дә йогышлы һәм агрессив булуы да шул вакытларда ныклап беленде. Башланып нибары бер ел узуга, ковид, барлык илләргә, кыйтгаларда да үтеп кереп, җәмгысы 110 миллион кешегә йогарга, бик күпләрне аяктан егып чирләтергә, 2,5 миллион кешенең гомерен дә өзәргә өлгерде. Әле аның белән генә дә бетмәде.

Пандемия тормышның барлык юнәлешләренә – сәясәт, икътисад, социаль өлкә, хәтта мәдәнияткә дә моңа кадәр күрелмәгән кире йогынты ясады, үз үзгәрешләрен кертте. Икътисад кризисы туды, фонд базарлары җимерелү чигенә килеп терәлде, энергия чыганаклары, углеводородларга бәя төште. Хәтта кибет киштәләреннән аерым төр азык-төлек юкка чыкты. Барыннан да авыры, әлбәттә, якыннарыбызны, таныш-белешләрне югалту булды. Шәхсән үземә килгәндә, туган-тумача арасында авыручылар булса да, үлем-китем очрагы, Аллага шөкер, килеп чыкмады. Тик якын һәм ераграк танышларым, мин бик тә хөрмәт иткән шәхесләрнең үлем хәбәре күздән яшьләрне чәчрәтеп чыгарды. Коточкыч авыр булды.

Кайсы яктан гына карасак та, ковид кешелек тарихында, ихтимал, иң дәһшәтле пандемияләрнең берсе булып калыр. «Калыр» дибез дә, чир тәгаен бетте микән соң әле? Чирләүчеләр бар гына түгел, кайсыбер тарафларда хәтта күп, бары үлем-китем очраклары гына чаң кагар дәрәҗәдә үк түгел әлегә. Бәлки вирусның яңа әшәке мутацияләр тудырыр алдыннан хәл генә җыеп ятуыдыр? 1990 нчы елларда Татарстан Югары Советы депутаты булган, хәзерге көндә Мәскәүдәге Үзәк икътисад-математика институтының баш гыйльми хезмәткәре, күпләребезгә таныш Иван Грачев пандемиянең кайтырына аз гына да шикләнми. Аның фикеренчә, COVID-19 – яшь вирус, үзенең бөтен мөмкин вариантларына кермичә, барысын да кешеләрдә, «практика»да сынап карамыйча тынычланмаячак. Бүген йомшаклык күрсәтүе, юашлыгы вакытлыча икән. Грачев, үзе төзегән математик модельгә таянып, яңадан бер ел, ел ярым дигәндә, вирусның үтә агрессив яңа штаммы яралачагын фаразлый һәм әзер булып торырга куша.

Шунысы да бар: галим-вирусологлар да кистереп, коронавирус кире кайтмаячак, усал штаммнар бүтән булмаячак, дими. Ул гынамы, әле бит таҗлы вирустан тыш та меңәрләгән төр вируслар бар. Алар барысы да без яшәгән тирәлектә, барысы да, бигрәк тә РНК-вирус дип аталганнары даими мутациядә. Микродөнья яңа сюрпризлар ясамас, дип кем әйтә ала? Бигрәк тә Җирдә климат үзгәргәндә, планетадагы уртача температура күтәрелеп барганда. Хәтсез галимнәр белдергәнчә, нәкъ менә температура үзгәрү вирусларга мутация өчен өстәмә стимул тудыра икән.

Ковидка кайтып дәвам иткәндә, аның килеп чыгышы турында бәхәсләр дә һаман тынмый. Кемдер аны табигать шуклыгы дип атаса, икенчеләр яшерен лабораторияләр тоткан зур дәүләтләрне гаепли. АКШ зәхмәтне тудыручы, аны дөньяга таратучы итеп Кытайны күрә. Россия бәлане, Украинадагы биолабораторияләргә бәйле рәвештә, АКШка ягарга тырыша. Шушы атна уртасында гына, АКШ сенатындагы тыңлауларда, илнең милли разведка идарәсе директоры Аврил Хейнс: «Махсус хезмәтләр COVID-19 яралуның ике версиясен – вирусның лабораториядән «качу»ын һәм табигый генезис вариантларын өйрәнә», – дип белдерде. Шул ук кеше: «Вирус, бактериологик корал буларак, кемдер тарафыннан махсус җитештерелгән, дигән шик бездә юк», – дип тә әйтте. Килеп чыгу җәһәтеннән хакыйкать кайчан да булса өскә калкыр, барысын да үз урынына куяр, дип артык өметләнеп булмый. Дөньяда бер-берсенә дошман көчләр яшәгәндә, берләшеп эш итү, хакыйкатьнең төбенә төшү турында сүз сөйләү гомумән урынсыз.

Вирус кешенең табигать алдында көчсез, зәгыйфь булуын җай чыккан саен исбатлап торганда, күпсанлы башка проблемалар хәл ителмәгәндә, дустанә яшәмәү, әлбәттә, бер мантыйкка да сыймый. Үзара дошманлык безнең сансызлык, беркатлылык белән янәшә. Кеше, кешелек җәмгыяте, үзен әллә кемгә санап, галәмне яулаучы, катлаулы технологияләр тудыручы, бөек ачышлар авторы итеп күрсә, күрергә теләсә дә, без булдырганнар табигать яраткан җан ияләре, шул исәптән аларның иңиң кечкенәләре белән чагыштырганда да бик примитив. Без ирешкәннәр – шактый вак казанышлар, үзебезне зурлау исә кыланчыклык һәм мактану гына. Табигать миллион еллар элек үк тудырган, кеше ифрат та аз белгән микродөнья безне, зурдан алганда, теләсә нишләтә ала. Бердән, алар мең, дистә мең төрдә. Икенчедән, алар безнең янәшәдә, алар эчебездә дә, тышыбызда да мыжгып тора. Вируслар – параллель дөнья, параллель цивилизация. Әле йөз дә ничә ел элек кенә аларның барлыгын да белүче булмаган. Бүген белгәннәребез дә ташка үлчим генә…

Сугыш кораллары ясауга киткән коточкыч күләмдәге акчаларның, көчнең яртысын гына микробиология, вирусологиягә юнәлткәндә, ул юнәлештәге белемнәребезне ун, йөз тапкыр арттыра алыр идек без. Бәлки әле эпидемия, пандемияләрне, гомумән йогышлы авыруларны бетереп тә булыр иде. Юк, кеше заты үз мөмкинлекләренең, көч, сәләтенең күп өлешен үз ишләре белән чәкәләшүгә, шуңа әзерлеккә, ызгышка, вату-җимерүләргә тота. Акыллы дип атап буламы соң андый җан иясен? Ихтимал, юктыр. Ковид бәйдән ычкынган мәлдә без постпандемия турында фикер йөрткән, адәми зат, бәла үтүгә, барысын да онытып, нәкъ элеккечә яши башлаячак, дигән идек. Барысы да рас килде – без үзгәрмәдек.

# Өйрәтәбез, сыныйбыз!

**Үзебезнекеләр үзебезгә кирәк! Мәгълүм булганча, Россия WorldSkills халыкара хәрәкәтендә әгъза булуын туктаткач, илнең Мәгърифәт министрлыгы урта һөнәри белем бирү йортлары студентлары, мәктәп укучылары өчен яңа ярыш уйлап тапты.**

«Татар-информ»

Хәзер кулы эш белгән егет-кызлар «Профессионаллар» һәм Югары технологияләр чемпионатларында осталык күрсәтәчәк. Тиздән төбәкләрдә, шул исәптән Татарстанда да сынау ярышлары башлана.

Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Андрей Поминов искәрткәнчә, ярышларны икътисадның реаль секторы ихтыяҗларына нигезләнеп оештырырга уйлыйлар. Ягъни биремнәр дә бүген һәм хәзер хәл итү юлларын таләп иткән мәсьәләләргә кагылачак. Ярышлар илне кадрлар белән тәэмин итү бурычын да хәл итәргә тиеш. Бигрәк тә сәнәгать предприятиеләре өчен белгечләр әзерләү юнәлешендә. Ярышларга бәя бирүче экспертлар төркемен дә киңрәк итмәкчеләр. Хәзер компания һәм предприятиеләрдән дә вәкилләр чакырылачак. Ярышта җиңүчеләргә һәм призерларга исә эш урыннары тәкъдим ителәчәк. Быел һәр компетенция буенча өчтән дә ким булмаган эш урыны белән кызыксындырырга җыеналар.

Россиянең WorldSkills хәрәкәтендә булмавы хәрәкәтнең үзенә дә тискәре йогынты ясамагае. Андрей Поминов әйтүенчә, бу хәрәкәтнең дөнья күләмендә үсеше өчен Россия аз тырышмады. Моның өчен соңгы елларда Казанда, гомумән, Россиядә үткән ярышларны искә алу да җитә.

Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге җитәкчесе Эмиль Гобәйдуллин әйтүенчә, яңа чемпионатка кушылучылар саны да көннән-көн арта. «Дөньякүләм үткән ярышлар белән чагыштырганда, бу чемпионат конкурсантлар, экспертлар һәм ярыш компетенцияләре саны буенча шактый зур», – ди Эмиль Гобәйдуллин. Россиянең WorldSkills хәрәкәтендә булмавына килгәндә исә, илнең дустанә башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләренә таянырга була, дигән фикердә ул.

**Кайда?** Республиканың 22 шәһәр һәм авылында барлыгы 82 мәйданчыкта.
**Кайчан?** 13 март – 7 апрель.
**Кемнәр катнаша?** 1903 катнашучы – 662 юниор (мәктәп баласы) һәм 1241 студент.
**Ничә компетенция?** 298. Шуларның 56сы сәнәгать җитештерүе тармагына бәйле.

# *Бүгеннән тотынасы*

**Рәсми Татарстан**

Халык белән эшне көчәйтергә кирәк! Бу һәм башка мәсьәләләр турында «Бердәм Россия» сәяси партиясе Татарстан төбәк бүлегенең сәяси советы президиумы утырышында фикер алыштылар. Киңәшмә төбәк бүлеге секретаре Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендә узды.

Чарада катнашучылар майда узачак өстәмә сайлауда «Бердәм Россия» партиясеннән тәкъдим ителәчәк кандидатлар өчен алдан тавыш бирүне үткәрү турында сөйләште. «Бердәм Россия» белән минем карьерам», «Бердәм мобилизация стандарты» кебек партия проектлары кысасындагы эшне дә карап тикшерделәр. Аерым алганда, «Бердәм Россия» белән минем карьерам» проекты кысасында партиянең Төбәк һәм зур шәһәрләрдәге иҗтимагый кабул итү пунктларында махсус үзәкләр эшли. Биредә мәшгульлек үзәкләре белгечләре халыкка яңадан уку һәм эшкә урнашуга бәйле сораулар буенча ярдәм күрсәтә.

– Көнүзәк мәсьәләләр турында фикер алыштык. Сораулар гадәттәгедән күбрәк тә иде. Бу алда торучы өч еллык сайлау кампаниясе циклына бәйле. Кадрлар резервы, җирле һәм беренчел бүлекчәләр белән эшне көчәйтү кирәклеге әйтелде. Бу – мөһим мәсьәлә, әлеге эшне барлык юнәлешләр буенча да алып барачакбыз, – дип сөйләде Фәрит Мөхәммәтшин соңрак журналистларга.

Аның әйтүенчә, җитәкчелектә үзгәрешләр бар. Киткәннәр урынына алмашка шундый ук оста, тырыш кадрлар киләчәк, дип тә ышандырды ул.

– Яңа билгеләнгән җитәкчеләр, эшне тиз арада отып алып, аны тагын да көчәйтә алсын өчен, әзерлекле кешеләрне тәкъдим иттем. Партия проектлары урыннарда да, гомумән, республика күләмендә дә «Бердәм Россия»нең абруен үстерүгә хезмәт итәргә тиеш, – диде партиянең төбәк бүлеге секретаре.

Киңәшмәдә катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, ул булачак сайлау кампанияләренә яхшы белгечләр җәлеп итүнең әһәмиятен тагын бер кат искәртте.

– Булачак кадрларны үзебезнең резервта торучы тиешле мәктәп узган, тәҗрибә тупларга өлгергән кешеләр арасыннан сайлап алырга кирәк. Килсеннәр дә шунда ук кертемнәр җыю, партия җыелышларын үткәрү кебек эшкә тотынсыннар. Бу җиңел түгел. Әлеге эш тәҗрибә, белем һәм җаваплылык таләп итә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ул сайлау кампаниясенең нинди чорда узачагын да тагын бер кат ассызыклады. Илгә ясалган басым партия вәкилләренә тагын да күбрәк җаваплылык өсти.

– Татарстанда сайлау циклы уңышлы узсын өчен, партиянең һәр буыны – башкарма комитеттан алып урыннардагы беренчел бүлекчәләргә кадәр барысы да бүген үк эшкә керешергә тиеш. Шул исәптән кадрлар сайларга, тарафдарлар сафларын арттырырга, яшьләр канатын ныгытырга, партия әгъзалары исемлеген барларга кирәк. Бу эшне безнең өчен башка беркем дә эшләмәячәк, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

# БАРЫСЫНА БЕР ТАРИХ

**Киләсе елдан мәктәпләрдә бердәм тарих дәреслекләре кертергә җыеналар. Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов аларның март аенда ук әзер буласын әйткән иде. Махсус хәрби операциягә дә аерым бүлек багышланачак. Бер басмага барысы да сыярмы? Аннан нәрсә көтәләр?**

Россия Мәгърифәт министрлыгы хәбәр иткәнчә, дәреслек дөнья һәм ил тарихын үз эченә алачак. Укучылар ил, дөнья вакыйгаларына кагылышлы сорауларга җавап эзли. Укытучылар аларга дөрес мәгълүмат табарга ярдәм итәргә тиеш. Президент ярдәмчесе, тарих дәреслекләрен төзү буенча эшче төркем җитәкчесе Владимир Мединский мәктәпләрдә тарихны саннар, даталар һәм фамилияләрне ятлатмыйча гына, кызыклы итеп үткәрергә киңәш итте.

Аксубай районы Сөнчәле мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Светлана Орлова белдергәнчә, тарих – зур проблема. 9 нчы сыйныфтан соң көллияткә киткән укучылар XX гасыр тарихын бөтенләй белми. Ни өчен дигәндә, ул темаларны бары 10–11 нче сыйныфларда гына үтәләр. Менә шул мәсьәлә борчый аны. Яңа дәреслекләрдә шуңа игътибар итсеннәр иде, ди.

– Бердәм дәреслек кирәк. Без бит совет мәктәбендә бер китаптан укыдык. Башка мәктәпкә күченеп киткәндә дә, кыенлыклар тумый иде. Яңа дәреслекләрне сузмыйча, тизрәк эшләсәләр яхшырак булыр иде, – ди Светлана Орлова.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Спас районы Иске Рәҗәп мәктәбенең тарих укытучысы Мәдинә Җамалиева фикеренчә, Россия тарихын гомуми тарих белән бергә алып бару һәм темаларны тирәнтен өйрәнү өчен, сәгатьләр санын арттыру да кирәк. Әмма туган як тарихын гомумиләштереп булмаганы көн кебек ачык.

– Һәр төбәк туган як тарихын аерым дәреслекләрдән өйрәнүне дәвам иттерсә яхшырак. Украинада барган вакыйгалар да, вакыт узгач, китапта үз урынын алыр. Әмма фашизмга нәфрәт һәм Бөек Ватан сугышындагы Кызыл армия батырлыгына рәхмәт, горурлык хисе тәрбияләүне һәр көнне алып барырга кирәк, – ди Мәдинә Җамалиева.

Яңа дәреслек турында Тарих институты директоры урынбасары, педагогика фәннәре кандидаты Марат Гыйбатдиновның да фикерен сораштык.

– Тарих буенча стандарт күптән эшләнде бит инде. Авторларга шуңа нигезләнеп язарга мөмкинлек тудырылды. Шуңа күрә берничә линия булырга мөмкин иде. Күрәсең, хәзер бер генә авторныкы булачак. Беренчедән, нинди дәреслек икәнен белмибез. Стандартта, һәр укучының сәләтенә карап, белем алуның шәхси траекториясен булдырырга, дип язылган иде. Бер генә дәреслеккә калдыру бу мөмкинлекне бирәме, юкмы? Менә бу – зур сорау. Яңа дәреслекләр биш ел саен яңартылып тора. Закон буенча шулай гына кулланырга ярый, – ди Марат Гыйбатдинов.

Дәресләр санының җитү-җитмәве белән дә кызыксындык.

– Нинди генә фән укытучысыннан сорасагыз да, җитми, диячәк. Бигрәк тә тарихтан. Ел саен материал артып тора. Җирле тарих белән дә проблема бар. Федераль стандартта, һәр бала үз төбәк тарихын белергә тиеш, диелгән. Ә сәгать җитмәсә, ничек белә ала ул аны? Бу инде укытучының кызыксынуыннан тора. Әгәр Россия тарихын укытканда, җирле компонентны куллана икән, бик әйбәт. Кызыксынмаганын бернишләтеп тә булмый. Бүген һәр төбәк өчен аерым дәреслек язарга йә өстәмә материаллар кертергә телиләр.

Сәрия МИФТАХОВА

# МУЛ УҢЫШ ТАМАК ТУЙДЫРАМЫ?

**Борчыган мәсьәлә**

**Фермерлар чаң кага. Бүген алар амбар тулы ашлыкларын кая куярга белми аптырый. Сатып җибәрерләр иде дә, алучысы юк. Сату булмагач, керем дә юк. Ә алда авыл хуҗалыгында җаваплы чор – язгы кыр эшләре тора.**

Бу проблема турында алардан моңа кадәр дә ишетеп белә идек. Ә узган атнада әлеге мәсьәлә республика дәрәҗәсендә кузгатылды. Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе корылтаенда оешма җитәкчесе Камияр Байтимеров амбарларда 6 млрд сумлык ашлыкның үз чиратын көтеп ятуын җиткерде.

– Узган ел фермерлар мул уңыш – 1 млн 321 мең тонна ашлык җыеп алды. Тик алар аны сата алмый. Бу хәл узган көздән үк килә. Проблеманы никадәр тизрәк хәл итсәк, алар шуның кадәр тизрәк язгы кыр эшләренә тотына алыр иде, – диде Камияр Байтемиров.

Соңрак бу проблема Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгының коллегия утырышында да әйтелде. Ул вакытта министр Марат Җәббаров:

– Безгә ашлыкның рекордлы уңышы аның бәясен төшергәнне дә исәпкә алырга кирәк. Бүген аның бер тоннасы 8 меңнән 11 мең сумга кадәр. Бу – узган ел белән чагыштырганда ике тапкыр азрак, – дигән иде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әлеге проблеманы ашлыкны терлекчелектә файдаланып хәл итәргә тәкъдим итте.

– Безнең республика терлекчелек белән шөгыльләнә. Логистика белән проблемаларны исәпкә алып, безгә ашлыгыбызны үз терлекчелегебез аша уздырырга кирәк, – диде ул.

Фермерлар аксакалы, Чүпрәле районында яшәп, озак еллар хуҗалык тотучы Равил Бикчуровка шалтыратып, аның фикерен белештек.

– Бүген барлык фермерлар алдында торган төп мәсьәлә бу, – диде ул. – Бүген алар ашлама да, гербицид та, солярка да ала алмый, чөнки ашлык сатудан акча керми. Алда – чәчү чоры, ә бит запас частьларга да, ашламага да, ягулыкка да бәя төшмәде. 2015 елда һәркайсын 5,5 млн сумга ике комбайн алган идек. Хәзер ул комбайннар 18 млн (!) сум тора. Өч ел элек 10 млн сум 600 меңгә яңа К-700 тракторы алдык. Бүген ул 17 млн сум тора. Күрәсезме, чыгымнар ничек зур? Складта яткан ашлык – үле капитал ул. Көнбагыш белән дә шул ук хәл. Узган ел без аны 50 сумнан саттык. Быел ул 25 сум 50 тиен тора. Мин бу проблемаларны Мәскәүдә узган съездда да сөйләп кайттым. Безгә хәзер нишләргә? Аптыраган…

Фермер фикеренчә, һәр нәрсә планлаштырып эшләнергә тиеш.

– Планлы икътисад кирәк, – ди ул. – Кем ни тели, шуны эшләү булырга тиеш түгел. Боларны контрольдә тотар өчен баш та, муен да кирәк. Элеваторларда азык-төлек запасын туплауны да дәүләт кайгыртсын иде. Эре агрохолдинглар белән генә эшләмичә, безгә дә игътибар булсын иде. Ашлыкны үстерү генә түгел, аңардан уңышлы табыш та алырга кирәк бит әле. Безнең кебек авылда нужа күреп, тырышып-тырмашып эшләүчеләргә ярдәм кайчан булыр икән ул?


«Татар-информ»

Әлеге хәл бер Татарстанда гына түгел. Ашлыкның чамадан тыш күплегеннән башка республика фермерлары да иза чигә. Съездда Башкортстан фермеры Зифкат Сәетгалиевнең ялкынлы чыгышын башкалар алкышларга күмде.

– Без узган ел 5 млн 300 мең тоннадан артык ашлык җыеп алдык, – диде ул. – Башкортстанга 2,5–3 млн тоннадан икмәк җитә. Димәк, бездә 2,5 млн тонна артык ашлык бар. Тик ул Свердловск өлкәсенә дә, Чиләбегә дә, Татарстанга да, Удмуртиягә дә кирәкми. Кыскасы, беркемгә кирәкми. Ә без аны ни дип үстердек? Продукцияне базарга кирәк кадәрле генә җитештерергә кирәк. Артык продукция исраф булмасын. Бу ашлык безгә кирәк, ләкин базарга кирәкми ул. Шулай булгач, аны кая да булса чыгарып чәчикмени?

Утырышта безнең янәшәдә утыручы фермерлар да, аның һәр җөмләсеннән соң диярлек: «Дөрес әйтә бит, чыннан да шулай», – дип кабатладылар.

Зифкат Сәетгалиев фикеренчә, ашлык бәясе 12 сумнан да кимрәк булырга тиеш түгел.

– Минем кечкенә генә хуҗалыктагы барлык амбарлар ашлык белән тулы. Бүгенгә мин аның дүрттән бер өлешен саттым. Калганнар анысын да сата алмый. Минем хәзер башымнан бер уй китми: яңа ашлыкны кая куярга? Мин бит аны 6 сумга сатып җибәрә алмыйм. Икътисад законы буенча, монысын сатмый торып, чәчәргә кирәкми. Элеваторлар да шәхси кулларга күчеп бетте, анда да саклап булмый, – диде ул.

Тик Әлмәт районы фермеры Наил Рәфыйков проблеманы артык күпертмәү яклы.

– Чәчмик, утыртмыйк, дигән сүзләр белән берничек тә килешә алмыйм, – ди ул. – Безнең әби-бабайларыбыз ат белән сөргән, кул белән эшләгән. Без дә эшләргә һәм илне туендырырга тырышабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

## Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 42 статьяда:
а) 5 өлештә «Үзара никахта торучы һәм баланы күтәрү өчен эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче затлар» сүзләрен «Баланы күтәрү һәм тудыру максатларында эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче үзара никахта торучы затлар, әгәр аларның берсе яисә икесе дә баланы күтәрү һәм тудыру турында шартнамә (алга таба – суррогат ана турында шартнамә) төзегән вакытта Россия Федерациясе гражданнары булып торса, яисә суррогат ана турында шартнамә төзегән вакытта Россия Федерациясе гражданы булган ялгыз хатын» сүзләренә алмаштырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 өлешләр өстәргә:
«6. Баланы күтәрү һәм тудыру максатларында эмбрионны башка хатынга имплантацияләргә язма рәвештә ризалык бирүче әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән затлар баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә, шулай ук Россия Федерациясе Гаилә кодексының 51 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән очракларда баланың ата-анасы булып язылырга мөмкин.
7. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән үзара никахта торучы затлар, бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсендә баланың ата-анасы булып язу вакытына аларның никахлары өзелгән яисә дөрес түгел дип танылган булса (ир йә хатынның берсе үлгән очрактан тыш), суд карары нигезендә һәм суд тарафыннан әлеге никах гаилә төзү ниятеннән башка булып төзелгән һәм туранындагы шартнамә төзү максатларында гына теркәлгән дип танылмаса, баланы тудырган хатын (суррогат ана) ризалыгы белән генә баланың ата-анасы булып языла ала. Суд мондый никах төзелү нәтиҗәсендә хокуклары бозылган ир йә хатынның (намуслы ир йә хатынның) баланың ата-анасы булып язылу хокукын таный.»;
2) 43 статьяның 4 өлешендә «ир һәм хатын» сүзләреннән соң «яисә ялгыз хатын» сүзләрен өстәргә.
**2 статья**
1. Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 статьясындагы 5 – 7 өлешләре нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) теркәлгән никах булу, шулай ук потенциаль ата-ананың берсенең йә ялгыз хатынның, йә суррогат ананың Россия Федерациясе гражданлыгы булу турындагы мәҗбүри шарт өлешендә суррогат ананың 2022 елның 19 декабренә торышына инде «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның (2022 елның 19 декабренә кадәр гамәлдә булган редакциядә) 55 статьясындагы 9 өлешендә күрсәтелгән потенциаль ата-ана йә ялгыз хатын белән төзелгән шартнамә нигезендә бала күтәрүе йә күрсәтелгән шартнамә нигезендә баланы тудыру очракларына кагылмый.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 9-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 1 статьяда «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;
2) 5 статьяда:
а) 1 өлешнең өченче абзацында «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;
б) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
3) 6 статьяның 7 пунктында «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;
4) 3 бүлек исемендә «терлекчелек продукциясенең» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;
5) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14 статья. **Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлау, төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу**
1. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыгын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен файдаланыла торган, капиталь төзелеш объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә һәм капиталь ремонтлаганда, капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызганда, терлекләрне асрау һәм терлек продукциясен җитештерү өчен федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) предметы кысаларында мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләргә туры килерлек, шул исәптән терлекләрнең йогышлы авырулары килеп чыгуны һәм таралуны кисәтү, терлек асраганда һәм терлек продукциясен җитештергәндә барлыкка килә торган калдыклар белән әйләнә-тирә мохитнең пычрануын кисәтү максатларында, шартлар тудыру каралырга тиеш.
2. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга (терлекләрне эшкуарлык эшчәнлегенә бәйле булмаган шәхси куллану өчен үстерүдән һәм асраудан тыш), терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга бәйле капиталь төзелеш объектын төзү һәм (яисә) капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар торгызу федераль дәүләт ветеринария контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органның бу капиталь төзелеш объектын, капиталь булмаган төзелмәне, корылманы планлаштырыла торган урнаштыруның федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) предметы кысаларында мәҗбүри үтәлергә тиешле таләпләргә туры килүе турында бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.»;
6) 16 статьяда:
а) исемдә «терлекчелек продукциясен» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;
б) 1 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга;
в) 2 өлештә «Терлекчелек продукциясен» сүзләрен «Терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;
7) 17 статьяда:
а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
8) 18 статьяда:
а) татарча текстта исем үзгәрешсез кала;
б) 1 өлештә:
татарча текстта беренче абзац үзгәрешсез кала;
икенче абзацта «терлекләрне асрауга, терлекчелек продуктларын җитештерүгә, эшкәртүгә, саклауга һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләрен «терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларны» сүзләренә алмаштырырга;
дүртенче абзацта «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «терлекчелек продуктларының» сүзләрен «терлек продукциясенең» сүзләренә алмаштырырга;
в) 2 өлештә «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга, «шушы продуктларны» сүзләрен «шушы продукцияне» сүзләренә алмаштырырга;
9) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«19 статья. **Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу**
1. Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юк иткәндә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясында күрсәтелгән затлар тәкъдиме буенча кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе ветеринария өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда юкка чыгару максатларында тартып алынырга мөмкин, мондый тартып алу турында милекчегә тиешле документ бирелергә тиеш.
2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән очракта терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе юкка чыгару максатларында терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу аркасында аңа килгән зыянны тартып алынган һәм юк ителгән терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясы нигезендә чикләү чаралары (карантин) билгеләү турында карар кабул ителгән көнгә кадәрге көнгә билгеләнгән бәясенә тигез күләмдә түләттерү хокукына ия, әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очрактан тыш.
3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең бәясе Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.
4. Терлекләрне үстерүгә һәм асрауга, терлек продукциясен җитештерүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга бәйле объектларда терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең милекчесе һәм (яисә) хуҗасы тарафыннан ветеринария өлкәсендәге Россия Федерациясе законнарын бозуга юл куелуы һәм аның федераль дәүләт ветеринария контроле (күзәтчелеге) кысаларында билгеләнүе ачыкланган очракта, бу объектларда терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килгәндә яисә таралганда милекчегә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан киметелергә яисә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү кире кагылырга мөмкин.
5. Зыянны түләү күләме киметелергә мөмкин булган очракларның исемлеге, мондый күләмне киметү тәртибе һәм зыянны түләү кире кагылырга мөмкин булган очраклар исемлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.
6. Тартып алына торган терлекләрнең һәм (яисә) терлек продукциясенең бәясен билгеләүгә, терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләү күләмен киметү турындагы карарга йә терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе бәясен түләүне кире кагу турындагы карарга терлекләр һәм (яисә) терлек продукциясе милекчесе тарафыннан судка шикаять белдерелергә мөмкин.
7. Терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары исемлеге һәм терлекләрнең аеруча куркыныч авырулары чыганакларын юкка чыгарганда терлекләрне һәм (яисә) терлек продукциясен тартып алу тәртибе Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.»;
10) 21 статьяның 3 өлешендә «терлекчелек продуктларын» сүзләрен «терлек продукциясен» сүзләренә алмаштырырга.
**2 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 10-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 9 статьяның 5 өлешендәге 10 пунктында «б» пунктчасында» сүзләрен «а» һәм (яисә) «б» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;
2) 11 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.
**2 статья**
«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 октябрендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 77 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:
«$2^1$. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «в» пунктчасындагы дүртенче абзацында каралган нигезләмә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында 2021 елның 1 апреленә кадәр төзелгән килешүләр нигезендә проектларны гамәлгә ашыра торган һәм Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә чыгымнарны каплый торган оешмаларга карата кулланылмый.».
**3 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 11-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр башкару капиталь ремонт өчен кертемнең әлеге Законның 9 статьясы нигезендә билгеләнгән минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финанслана торган әлеге хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге үз эченә Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне ала. Хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең әлеге исемлегенә кертелгән хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган методик тәкъдимнәр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.»;
2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:
«$1^1$. Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлегенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә фасадны җылыту, җылләтелми торган түбәне җылләтелә торган түбә итеп үзгәртеп кору, түбәгә чыгу юлларын ясау, коммуналь ресурслар куллануны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләрне исәпләүнең автоматлаштырылган мәгълүмат-исәп системаларын урнаштыру, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпләүнең күмәк (гомумйорт) җайланмаларын һәм әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) кулланугa идарә итү һәм аны җайга салу узелларын урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр, башка төр хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр өстәлергә мөмкин.».
**2 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 12-ТРЗ

## «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) унөченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда эш иткән, әгәр шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга җәлеп ителүче янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составы, янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, янгын сүндерүдә башка катнашучылар матди зыян китергән өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.»;
2) түбәндәге эчтәлекле унбишенче өлеш өстәргә:
«Акланган куркыныч һәм (яисә) аеруча кирәкле шартларда эш иткән, әгәр шул ук вакытта аеруча кирәклелек чикләре арттырылмаса, янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруга җәлеп ителүче янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составы, янгын сүндерү җитәкчесен дә кертеп, янгын сүндерүдә башка катнашучылар коткарылучы кешеләрнең, янгыннан саклану хезмәтенең шәхси составының, янгын сүндерүдә башка катнашучыларның сәламәтлегенә зыян китергән яисә аларның һәлак булуы өчен җаваплылыктан Россия Федерациясе законнары нигезендә азат ителергә мөмкин.».
**2 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 13-ТРЗ

## «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 8; 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 1 – 2, № 4, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 7 пунктта «урта һөнәри белемнең һәм югары белемнең уку-укыту программаларын федераль дәүләт мәгариф стандартларына туры китереп гамәлгә ашырырга,» сүзләрен «федераль дәүләт мәгариф стандартлары таләпләре нигезендә урта һөнәри белемнең уку-укыту программаларын, бакалавриат программаларын, специалитет программаларын һәм магистратура программаларын, федераль дәүләт таләпләренә туры китереп аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын,» сүзләренә алмаштырырга;
2) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:
«$9^1$. Аспирантурада федераль дәүләт таләпләре нигезендә фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын гамәлгә ашыручы дин белеме бирү оешмалары йомгаклау аттестациясе узган затларга фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алу өчен диссертациянең «Фән турында һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте хакында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законга таянып билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә һәм аспирантураны тәмамлау хакында таныклык бирәләр.».
**2 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 14-ТРЗ

## «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 6 статьяның 4 пунктында «(әлеге Законның 12 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән урыннардан гайре)» сүзләрен төшереп калдырырга;
2) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12 статья. **Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар**
Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар Федераль закон нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**
Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 15-ТРЗ

## Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**
Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 22 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;
2) 23 статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләреннән соң «, шул исәптән инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара хезмәттәшлек турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;
3) $23^1$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында «шартнамәләр (килешүләр)» сүзләреннән соң «, шул исәптән инфраструктураны бергә үстерү өчен якларның берсе шәһәр округы булган муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр» сүзләрен өстәргә;
4) $29^3$ статьяда:
а) 2 пунктта «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары,» сүзләрен «әлеге статьяның 3 – 5 пунктлары, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга, «, инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан финанс хисабы елы ахырына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертлардан, юридик затлардан максатчан билгеләнешкә ия кире кайтарылмый торган акчалардан, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары нисбәтлелеген тәэмин итү чараларына ярдәм күрсәтүгә файдалану шартлары билгеләнеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджетына дотацияләрдән тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар күләменә, шулай ук финанс хисабы елының ахыргы эш көненнән соң Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән, шул исәптән акчаларның ахыргы әйләнешләрен үткәрү тәртибендә, финанс хисабы елы керемнәре акчалары күләменә артыграк булырга мөмкин.
Акчаларның ахыргы әйләнешләре дигәндә, финанс хисабы елына караган, әмма чираттагы финанс елы башында Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тапшыруның билгеләнгән срогына кадәр үткәрелгән счетлар буенча акчалар әйләнешләре (алга таба әлеге статьяда – акчаларның ахыргы әйләнешләре) аңлашыла.
Финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы, финанс хисабы елы йомгаклары буенча әлеге пунктның беренче абзацында каралган ихтимал булган арттыруларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, Татарстан Республикасы бюджетының күрсәтелгән арттыру суммасындагы агымдагы финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән калган акчалары әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктында каралган максатларга агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп юнәлдерелергә тиеш.»;
в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Финанс хисабы елында муниципаль берәмлек хисаплашуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан финанс хисабы елы ахырына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертлардан, юридик затлардан максатчан билгеләнешкә ия кире кайтарылмый торган акчалардан, Татарстан Республикасы бюджетыннан файдалану шартлары билгеләнеп бирелгән җирле бюджетлар нисбәтлелеген тәэмин итү чараларына ярдәм күрсәтүгә җирле бюджетларга дотацияләрдән яисә җирле бюджетларга башка дотацияләрдән тулысынча файдаланмауга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар күләменә, шулай ук финанс хисабы елының ахыргы эш көненнән соң җирле бюджетка күчерелгән, шул исәптән акчаларның ахыргы әйләнешләрен үткәрү тәртибендә, финанс хисабы елы керемнәре акчалары күләменә артыграк булырга мөмкин.
Финанс хисабы елында муниципаль берәмлек хисаплашуларының гомуми суммасы, финанс хисабы елы йомгаклары буенча әлеге пунктның беренче абзацында каралган ихтимал булган арттыруларны исәпкә алып, җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, җирле бюджетның күрсәтелгән арттыру суммасындагы агымдагы елның 1 гыйнварына барлыкка килгән калган акчалары әлеге Кодексның 25 статьясындагы 5 пунктында каралган максатларга агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп юнәлдерелергә тиеш.»;
г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бюджет кредитлары бирү тәртибендә җирле бюджетларга бюджет кредитлары, шулай ук инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет кредитлары бирү каралган булса, Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән әлеге бюджет кредитларына әлеге статьяның 2 һәм 3 пунктлары нигезләмәләре кагылмый.»;
5) 31 статьяның $4^1$ пунктында:
а) «Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме» сүзләреннән соң «(Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган очрактан тыш)» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бурычының күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бурычының югары чигеннән, шул исәптән эчке дәүләт хисаплашулары программасы күрсәткечләреннән, федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бирелгән бюджет кредитлары суммасына артыграк булырга мөмкин, әмма чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты хакындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган, кире кайтарылмый торган акчаларның расланган күләмен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменең 100 процентыннан артык булмаска тиеш.»;
6) $44^{2.1}$ статьяның 1 пунктында «финанслашу максатларында» сүзләреннән соң «, шул исәптән төзү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә торган инфраструктураны бергә үстерү өчен регионара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;
7) $44^5$ статьяның $4^2$ пунктындагы икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасының җирле бюджетларга җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкаруга финанс ярдәме күрсәтү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирү буенча чыгым йөкләмәсе финанслашкан очракта, әлеге килешүләр Россия Федерациясе Бюджет кодексының $132^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән килешүләр өчен Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган типлаштырылган рәвеш кебек үк рәвеш буенча төзеләләр.»;
8) $44^{11}$ статьяның 1 пунктында «финанслашу максатларында» сүзләреннән соң «, шул исәптән төзү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган инфраструктураны бергә үстерү өчен якларның берсе шәһәр округы булган муниципальара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;
9) 45 статьяның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
10) 49 статьяда:
а) икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
б) илле җиденче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
11) $51^1$ статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
12) 53 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;
13) $53^3$ статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
14) 60 статьяның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
15) 61 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
16) 63 статьяда:
а) 3 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
17) 67 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
18) 69 статьяда «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;
19) 70 статьяда:
а) икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;
б) өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
20) 71 статьяда:
а) исемендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
б) «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;
21) 78 статьяның 3 пунктында:
а) беренче абзацта «һәм элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Бюджет акчаларын алучы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы башка федераль законнар нигезләмәләрендә каралган очракларда, дәүләт контрактлары, башка шартнамәләр буенча йөкләмәләрне бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан соң башкару каралган мондый дәүләт контрактлары, башка шартнамәләр төзи. Дәүләт контрактлары, башка шартнамәләр төзү өчен билгеләнгән әлеге нигезләмәләр шулай ук элек төзелгән дәүләт контрактларына, башка шартнамәләргә үзгәрешләр керткәндә кулланыла.»;
22) 93 статьяның 3 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
23) $97^4$ статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
24) $97^6$ статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.
**2 статья**
«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш), «2025 елның» сүзләрен «2026 елның» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.
**3 статья**
1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы, $23^1$ статьясының 1 пунктын-

дагы икенче абзацы, 31 статьясының $4^{1}$ пункты, $44^{2.1}$ статьясының 1 пункты, $44^{5}$ статьясының $4^{2}$ пунктындагы икенче абзацы, $44^{11}$ статьясының 1 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын үтәгәндә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 16-ТРЗ

## «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 22 февралендә кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында»;**

2) 1 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил»;**

б) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 статьяда:

а) 1 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзаларының, алар тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләре гамәлгә ашырылуга бәйле рәвештә)» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзалары, алар тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләре гамәлгә ашырылуга бәйле рәвештә)» сүзләрен өстәргә;

5) 5 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^{1}$ пункт өстәргә:

«$7^{1}$) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен карау кысаларында махсус рөхсәттән башка Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан сак астында тоту урыннарына һәм мәҗбүри эшләр, кулга алу, иректән мәхрүм итү рәвешендәге җинаять җәзаларын үтәтү учреждениеләренә Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы беренче – дүртенче өлешләрендә һәм $159^{1}$ – $159^{3}$, $159^{5}$, $159^{6}$, 160, 165 һәм 201 статьяларында каралган җинаятьләр, әгәр әлеге җинаятьләр индивидуаль эшкуар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм (яисә) аныкы булган, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдаланыла торган мөлкәт белән идарә итүгә бәйле рәвештә кылынган булса йә әлеге җинаятьләр коммерциячел оешманың идарә органы әгъзасы тарафыннан мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә йә коммерциячел оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген яисә башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кылынган булса, шулай ук Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы бишенче – җиденче өлешләрендә һәм 171, $171^{1}$, $171^{3}$ – $172^{3}$, $173^{1}$ – $174^{1}$, 176 – 178, 180, 181, 183, 185 – $185^{4}$ һәм 190 – $199^{4}$ статьяларында каралган җинаятьләр турындагы эшләр буенча шик белдерелә торган, гаепләнә торган һәм хөкем ителгән затлар хокукларын яклау максатларында кереп йөрергә;»;

8) 13 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9) 14 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 09 март. № 17-ТРЗ

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «ТАИФ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Шиһабетдинов** Альберт Кашаф улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Александр Невский ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен: В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең технологик үсеш үзәге проект офисы баш эксперты **Газизов** Илһам Гарифҗан улы; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе электр белән кулдан эретеп ябыштыручысы **Зубарев** Анатолий Иванович; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте идарәсе башлыгының беренче урынбасары – баш инженеры **Любецкий** Сергей Владимирович Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнделәр.

* * *

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстанның медицина техникасы һәм формациясе» дәүләт унитар предприятиесенең Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы 60 номерлы район үзәк даруханәсе мөдире урынбасары **Шәфыйкова** Йолдыз Габдрахман кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

* * *

В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте «Татнефть-Добыча» структур подразделениесенең Ромашкино ятмасы – «Север» ятмаларын эшкәртү бүлеге төркеме баш белгече **Тарасова** Анна Ивановнага Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган геологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Фәнни эшчәнлегендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Геология һәм нефть-газ технологияләре институты директоры, геология-минералогия фәннәре докторы, профессор **Нургалиев** Данис Карловичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Фәнни-педагогик эшчәнлегендәге, квалификацияле белгечләр әзерләүдәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү-техник университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе кафедрасы профессоры **Евдокимов** Юрий Кирилловичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләүләре өчен: В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе технологик җиһазлар ремонтлау буенча слесаре **Айкин** Владимир Владимировичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе нефть һәм газ чыгару департаменты идарәсе башлыгы урынбасары – бүлек башлыгы **Әхмәдуллин** Роберт Рафаэль улына; «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Лениногорскнефть» нефть-газ чыгару идарәсе җир асты катламнары басымын саклау буенча операторы **Галиев** Мөнир Миңнулла улына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең скважиналарны җир астында ремонтлау буенча Җәлил цехының скважиналарны җир астында ремонтлау буенча операторы **Галиев** Рөстәм Әсләх улына; «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Прикамнефть» нефть-газ чыгару идарәсе инженер-технологы (алмашып эшләүче) **Глазков** Сергей Владимировичка; «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсе цех башлыгы **Җәлилов** Рәмис Якуб улына; «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Җәлилнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Ихсанов** Алис Унип улына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Леонтьев** Валерий Михайловичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе нефть һәм газ чыгару департаменты төркеме җитәкчесе **Сандулов** Олег Михайловичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Азнакайнефть» нефть-газ чыгару идарәсе цех башлыгы **Сучков** Андрей Николаевичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Филимонов** Сергей Ивановичка; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең нефть һәм газ чыгару буенча операторы **Хәсәншин** Илдус Гаделша улына; В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе ремонт-механика остаханәсе башлыгы **Хафизов** Рәхим Расыйх улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Мәгариф һәм яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләүдәге зур казанышлары, гражданлык бурычын үтәүдә күрсәткән югары дәрәҗәдәге мораль, әхлакый һәм рухи сыйфатлары өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Ибраһимов** Сәгыйть Габдерәүф улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Машина төзү өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Түбән Кама механика заводы» акционерлык җәмгыятенең электр җиһазларын ремонтлау һәм карап тоту буенча электромонтеры **Мансуров** Фәргать Тәлгать улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Грац шәһәрендә (Австрия Республикасы) узган «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә һөнәри осталык буенча Европа чемпионатына Россия Федерациясе илкүләм җыелма командасын уңышлы әзерләүне тәэмин иткән өчен «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры урынбасары **Рамазанова** Дамирә Акмал кызы Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Машина төзү өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Түбән Кама механика заводы» акционерлык җәмгыятенең слесарь-ремонтчысы **Фәтхетдинов** Рәис Җәүдәт улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең бутил каучук заводы дегидратация аппаратчысы **Мартьянов** Владимир Николаевич Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Кудрявцева** Алевтина Николаевна **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Дәүләт химия продуктлары фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесе директоры **Гатина** Роза Фатыйх кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика суд-медицина экспертизасы бюросы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – суд-медицина эксперты – мәетләргә экспертиза уздыру бүлеге Чистай районара суд-медицина бүлекчәсе мөдире **Исаев** Владимир Александровичка, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе стационарының терапия бүлекчәсе мөдире – табиб-терапевты **Мальковская** Светлана Алексеевнага, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча медицина-санитария часте» федераль казна сәламәтлек саклау учреждениесе госпитале поликлиникасының (Чаллы шәһәрендә урнашкан) стоматология кабинеты табибы – стоматолог-терапевты **Мәхмүтова** Илсөяр Газиз кызына, «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Кузайкино участок хастаханәсе гомуми практика табибы (гаилә табибы) **Назаров** Петр Николаевичка, «Әлмәт шәһәре һәм «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең медицина-санитария часте» дәвалау-профилактика учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Нуруллин** Рәшит Фиат улына, «Лениногорск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең хатын-кызлар консультациясе табиб-терапевты **Сипаева** Рәшидә Сөләйман кызына, «Азнакай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең стоматология бүлекчәсе табибы – стоматолог-хирургы **Фәрхуллин** Илфат Нургали улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең фәнни-тикшеренү бүлеге баш фәнни хезмәткәре **Скворцов** Алексей Петровичка **«Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

6 март, 2023 ел Казан ш. № 10/69

**Төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы басмалар исемлеге турында**

«Россия Федерациясендә гражданнарның сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» 12 июнь, 2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 47 статьясындагы 7, 8 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 57 нче статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карар бирә:

2023 елның 28 маенда 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау үткәргәндә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тапшырган Төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы басмалар исемлеген (кушымта итеп бирелә) игътибарга алырга.

2023 елның 28 маенда 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау өчен Төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы басмалар исемлеген «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

Бу карарны һәм 2023 елның 28 маенда 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау өчен төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы басмалар исемлеген Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары А.А.Нефедовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау Комиссиясенә Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе тапшырды

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 6 март, 2023 ел, № 10/69 карарына кушымта

**2023 елның 28 маенда 20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлау өчен төбәк дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, төбәк дәүләт һәм муниципаль вакытлы басмалар исемлеге**

**20 нче Электротехник бер мандатлы сайлау округы**

**Төбәк дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Телерадиотапшырулар оешмасы атамасы | Бу оешма чыгара торган массакүләм мәгълүмат чарасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын вакытлы тарату формасы (телеканал, радиоканал, телепрограмма, радиопрограмма) | Телевидение тапшыруларына, радио тапшыруларына лицензиясе нигезендә, массакүләм мәгълүмат чарасын тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Телерадиотапшыру оешмасының юридик адресы | Телерадиотапшыру оешмасының гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары өлеше (кертеме) | Аны эшләтүгә федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре төре | Аны эшләтүгә федераль бюджеттан, Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре күләме | Тиешле телеканал, радиоканалның (телепрограмма, радиопрограмма) махсуслашкан булу-булмавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | ВГТРК ФГУП – «Татарстан» ГТРК филиалы | Россия радиосы | Радиоканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 76123 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 2. | ВГТРК ФГУП – «Татарстан» ГТРК филиалы | «Россия» телеканалы (Россия - 1) | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 76122 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 3. | ВГТРК ФГУП –«Татарстан» ГТРК филиалы | «Россия - 24» Россия мәгълүмат каналы (Россия - 24) | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 48108 | 24.06.2019 | 420095, Казан ш., Горький ур., 15 й. | Россия Федерациясе Хөкүмәте | 100% | Дәүләт контрактлары | - | - |
| 4. | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте | «Татарстан-Яңа Гасыр» радиосы | Радиоканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 79339 | 02.11.2020 | 420095, Казан ш., Шамил Усманов ур., 9 й. | «Таиф» ААҖ, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 48,421% | Субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | - |
| 5. | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте | «Татарстан-Яңа Гасыр» телевидениесе | Телеканал | Россия Федерациясе | ЭЛ № ФС 77 - 79341 | 02.11.2020 | 420095, Казан ш., Шамил Усманов ур., 9 й. | «Таиф» ААҖ, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | 48,421% | Субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | - |
| 6. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | Кама-ТВ. Чаллы | Телеканал | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ЭЛ № ТУ 16 - 01468 | 11.02.2016 | 420097, Татарстан Респ., Казан ш., Академия ур., 2 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | - |
| 7. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | «Күңел» радиосы | Радиоканал | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ЭЛ № ТУ 16 - 01722 | 31.12.2020 | 420097, Татарстан Респ., Казан ш., Академия ур., 2 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | - |
| 8. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | «Телекомпания «Чаллы - ТВ» («Телекомпания «Челны-ТВ») | Телеканал | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ЭЛ № ТУ 16 - 01540 | 19.01.2017 | 420097, Татарстан Респ., Казан ш., Академия ур., 2 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | - |

**Төбәк вакытлы матбугат басмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Вакытлы матбугат басмасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык нигезендә, аны тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Вакытлы матбугат басмасы редакциясенең юридик адресы | Вакытлы матбугат басмасының, басма матбугат редакциясенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары өлеше (кертеме) | Аны эшләтүгә Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре төре | Аны эшләтүгә Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре күләме | Вакытлы матбугат басмасының чыгу ешлыгы | Вакытлы матбугат басмасының махсуслашкан булу-булмавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | Ватаным Татарстан | Россиядә татарларның компактлы яшәү урыннары (Татарстан Республикасы (Татарстан) | № 430 | 21.06.1995 | 420097, Татарстан Респ., Казан ш., Академия ур., 2 й. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты; «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты | 100% | субсидияләр | - | Атнага 4 тапкыр | - |
| 2. | Республика Татарстан | Татарстан Республикасы (Татарстан), шулай ук татарларның БДБ илләрендә компактлы яшәү урыннары | № 429 | 21.06.1995 | 420097, Татарстан Респ., Казан ш., Академия ур., 2 й. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты; «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 100% | субсидии | - | Атнага 4 тапкыр | - |
| 3. | События недели | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ТУ 16 - 01139 | 09.01.2014 | 420066, Татарстан Республикасы, Казан ш., Декабристлар ур., 2 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | 100% | Субсидияләр һәм дәүләт контрактлары | - | Атнага 1 тапкыр | - |
| 4. | Челнинские известия | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ФС7 - 4783 | 30.11.2007 | 423827, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Яшь Ленинчылар бульвары, 9 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | Атнага 2 тапкыр | - |
| 5. | Шәһри Чаллы | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ТУ 16 - 01677 | 02.10.2019 | 423827, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Яшь Ленинчылар бульвары, 9 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | Атнага 2 тапкыр | - |
| 6. | Якты юл | Татарстан Республикасы (Татарстан) | ПИ № ТУ 16 - 01012 | 16.05.2013 | 423807, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Муса Җәлил проспекты, 46 й. | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте | - | - | - | Атнага 2 тапкыр | - |

**Муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Телерадиотапшырулар оешмасы атамасы | Бу оешма чыгара торган массакүләм мәгълүмат чарасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын вакытлы тарату формасы (телеканал, радиоканал, телепрограмма, радиопрограмма) | Телевидение тапшыруларына, радиотапшыруларына лицензиясе нигезендә, массакүләм мәгълүмат чарасын тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Телерадиотапшыру оешмасының юридик адресы | Телерадиотапшыру оешмасының гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталында муниципаль берәмлекләрнең өлеше (кертеме) | Аны эшләтүгә җирле бюджеттан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре төре | Аны эшләтүгә җирле бюджеттан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре күләме | Тиешле телеканал, радиоканалның (телепрограмма, радиопрограмма) махсуслашкан булу-булмавын күрсәтергә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

**Муниципаль вакытлы матбугат басмалары турында мәгълүматлар**

| № п/п | Вакытлы матбугат басмасы атамасы | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык нигезендә, аны тарату территориясе | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкның теркәү номеры | Массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклыкны бирү датасы | Вакытлы матбугат басмасы редакциясенең юридик адресы | Вакытлы матбугат басмасының, басма матбугат редакциясенең гамәлгә куючысы (гамәлгә куючылары) | Устав (җыелма) капиталында муниципаль берәмлекләрнең субъектлары өлеше (кертеме) | Аны эшләтүгә җирле бюджеттан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре төре | Аны эшләтүгә җирле бюджеттан бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре күләме | Вакытлы матбугат басмасының чыгу ешлыгы | Вакытлы матбугат басмасының махсуслашкан булу-булмавын күрсәтү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

**«ВТ» – 105** 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

# СҮЗ ҺӘМ ҖАВАПЛЫЛЫК

**Басма матбугат үләчәк, газета-журналларны укучылар калмаячак. Мондый сүзләр 24 ел элек, мин Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга кергәндә үк ишетелә иде инде. Республиканың төп дәүләт басмасы «Ватаным Татарстан»га 105 ел тулган көннәрдә бу хакта күбрәк уйландыра. Ә бүген басма матбугатның роле нинди?**

105 еллык тарихта төрле чорлар булган. Ачлык еллары, Сталин репрессияләре, Бөек Ватан сугышы, торгынлык һәм үзгәртеп корулар… Ә милләт язмышы? Телдән һәм диннән биздерергә маташулар – үзәкләргә үткән, җаннан кан койдырган тарих сәхифәләре… Газета битләре боларның барысын да сыйдырган, киләчәк буын ул ялгышларны кабатламасын өчен, «ташка бастырып» калдырган.

Олпат басмага мөхәррирлек итә башлау минем өчен дә шактый кыен чорга туры килде. Бихисап идеяләрнең шактые тартмага салынды, вакыты да, мөмкинлекләре дә ул түгел. Пандемия чорында берничә ай өйдән дә чыкмыйча атнага дүрт тапкыр яңа сан әзерләү, онлайн планеркалар һәм киңәшмәләр, укучы белән күрешергә дә зар була торып, аны биздермәслек газета чыгарырга тырышу. Ул зәхмәттән айнып та өлгермәс борын, ил яңа сынау алдына басты – махсус хәрби операция. Ватан һәм Ватанны саклау төшенчәләренең әһәмияте, ватанпәрвәрлек, чикләүләр һәм кыенлыклар – болар турында ишетеп кенә белгән буынга бу хакта алар аңларлык итеп ничек сөйләргә? Сынауның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген ничек күңелләренә сендерергә?

Фейклар һәм хайп белән тулган интернетта нәрсәнең чын, нәрсәнең ялган икәнен аера алмый аптыраган халык күп соравына җавапны «Ватаным Татарстан»нан тапты һәм таба дисәм, һич кенә дә арттыру булмас. Бу мактану түгел, бу – дәүләт массакүләм мәгълүмат чараларының, аерым алганда, басма матбугатның роле зур икәнне күрсәтә торган дәлил.

Басма матбугатның бетәчәге турында сөйләү кайчак сүз булмаганнан гына сөйләнү кебек тоела. Ничек кенә булмасын, соңгы еллардагы вазгыять басма матбугатның ролен күрсәтте – аңа ышаныч бар. Безнең халыкта «ташка басылган» дигән төшенчә бар. Ташка басылганнан качып та, аны бетереп ташлап та булмый. Нәрсәнедер ачыкларга кирәк булганда, без архивтан 40, 50, 60 ел элек чыккан газеталарны күтәреп карыйбыз. Карыйбыз һәм… безне дә шулай укыячаклар, дип уйлыйбыз. Тарих язабыз бит! Юк, без хыялый түгел, очрашулар вакытында ветераннарыбыз искә алган йөзәрләгән мең тираҗлар турында хыялланмыйбыз. Бүгенгесен саклау да – зур эш! Басма газетадан тыш, интернетта да «Ватаным»ны тәүлегенә 12–13 меңнән артык кеше укый. Анысы да – зур сан.

Журналистикага зур ишекне мин «Ватаным» аша ачтым. Ул – минем беренче эш урыным. Безнең буын өчен тәҗрибә мәктәбе булган журналистлар белән, алар инде биредә эшләмәсә дә, һәрдаим аралашабыз. Безнекеләр бит алар, Үзебезнекеләр! Чорлар, кешеләр үзгәрә, тик «Ватаным Татарстан»дагы Сүз өчен Җаваплылык хисе беркайчан да кимеми. Шул хисне безгә сеңдергән өчен рәхмәт сезгә, гасырдан артык тарих язган ветераннар! Шул хисне тагын да арттырып, безгә таләпчән булганыгыз өчен рәхмәт сезгә, кадерле укучылар! Сез булганда, без бар. Бәйрәмебез уртак булсын!

Яратып, баш мөхәррир
Гөлнара САБИРОВА

Редакция коллективы даими авторларга аерым рәхмәтле. Менә алар: Зыятдин Вәлиәхмәтов, Әсгать Сәгыйтдинов, Нурисә Габдуллина, Рәзимә Кашапова, Миңзифа Хөснетдинова, Равилә Мөбарәкшина, Нәсимә Камалиева, Ләйлә Шиһабиева, Ризилә Корбанова, Миләүшә Ягъфәрова.

## ГАЗЕТАНЫҢ ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАГЫ ИСЕМНӘРЕ

- «Эш» (1918–1920 еллар).
- «Татарстан хәбәрләре» (1920–1922 еллар).
- «Татарстан» (1922–1924 еллар).
- «Кызыл Татарстан» (1924–1951 еллар).
- «Совет Татарстаны» (1951–1960 еллар).
- «Социалистик Татарстан» (1960–1992 еллар).
- «Ватаным Татарстан» (1992 елдан).

## РЕДАКЦИЯ УРНАШКАН УРЫННАР

- Лобачевский урамы, 31 нче йорт (1918 елның май ае – 1918 елның август ае).
- Мәскәү урамы, 57 нче йорт (1918 елның 9 сентябре – 1919 елның 25 феврале).
- Тукай урамы, 31 нче йорт (1919 елның 25 феврале – 1919 елның гыйнвары).
- Бауман урамында соңрак шахмат клубы булган йорт (1923 ел).
- Дзержинский (элеккеге Черноозерский) урамы, 29/1 нче йорт (1923–1924 еллар).
- Кремль (элеккеге Ленин) урамындагы йорт (1924–1935 еллар).
- Бауман урамы, 19 йорт (1935–1974 еллар).
- Декабристлар урамы, 2 нче йорт (1974–2010 еллар).
- Академия урамы, 2 нче йорт (2010 елдан).

# ШӘМСИ АГА МӘКТӘБЕ

**Шәмси ага Хамматов мәктәбен үткән кешеләр үзләрен бәхетле саный. Ни өчен? Чөнки ул безне тәртипле булырга, башкаларны ихтирам итәргә, милли мәнфәгатьләр өчен көрәшергә, каләм, сүз бәясен белергә өйрәтте. Бу зур, ышанычлы мәктәп иде. Шәмси ага аңлатканнар, әйткәннәр актуальлеген беркайчан да югалтмады.**

Бүген Шәмси Хамматовның эшенә дөрес бәя биреп, аның исемен мәңгеләштерү (1000 еллык Казаныбызда, һичшиксез, аның исемендәге урам, китапханә яисә мәдәният сарае, ә бәлки Журналистлар берлеге йорты булырга тиеш) бик урынлы булыр иде.

«Социалистик Татарстан» газетасына эшкә алуны үтенеп язган гаризамны тапшыру өчен, мөхәррир Шәмси Хамматов бүлмәсенә кердем. Беренче эш итеп, ул минем кайсы төбәктән булуымны сорады: «Татар телен беләсеңме соң? Районыгызда нигездә руслар яши бит», – диде ул, шаярткан булып, һәм ни дәрәҗәдә ана телен белүем белән кызыксынды. «Әйе, беләм, мин бит – саф татар авылы кызы», – дидем. Өч ел буена язу машинкасында чыныгу алгач, канцеляриягә эшкә күчерделәр. Вазыйфама хезмәткәрләрнең шәхси документлары, мөһим кәгазьләр белән эшләү йөкләнде. Турыдан-туры Шәмси аганың кул астында эшләргә, пөхтә, сабыр, әдәпле, хезмәткәрләргә аерата игътибарлы булырга, тынычландыру чарасын да, гозерләрен үтәү юлларын да таба белергә кирәк иде. Бик еш түрәләр, аларның ярдәмчеләре белән дә сөйләшергә туры килде. Мондый чакларда аерата җаваплы булырга, сүз кадерен белергә кирәк, ялгыш кына да хата җибәрергә ярамый. Шул вакытта Шәмси аганың: «Син бер дә борчылма, сеңлем, елмаеп кына эндәш», – дигән киңәшләре, белемеңне күтәрергә менә бу китаплар да ярдәм итми калмас дип, әдәплелек, дипломатия хезмәте, телефоннан ничек сөйләшү кагыйдәләрен эченә алган китапларны кулыма тоттыруы хәтеремдә. Мин хәзер дә ул китапларны кат-кат укыйм.

Шәмси ага күп вакытын бюро, президиум утырышларында, төрле киңәшмәләрдә үткәрсә дә, редакциягә кайтып җыелыш уздырырга да, төпле киңәшләрен бирергә дә, газетада чыгачак материалларны карап, тикшереп, кирәк булса, редакцияләп чыгарга да өлгерә иде. Йомышны кушканда да сүзен: «Бу эшне башкару сезгә авыр булмасмы икән?» – дип башлады. Эшне тәмамлаганнан соң: «Бик зур рәхмәт», – дип, итагатьлелек күрсәтеп, эшне бәяли белде.

Пөхтәлеге, зәвыклы киенүе, кешелекле булуы белән дә аерылып торды ул. Гадилеге белән җәлеп итте. Пөхтәлекне хезмәткәрләрдән дә таләп итә белде. Көндәлек җыелышларда, һәрбер кешене игътибар белән күзәтеп чыкканнан соң, фамилияне әйтеп түгел, ә гомумиләштереп: «Торба чалбарлар» яисә «бик үк саф булмаган килеш редакциягә эшкә килмәсәгез дә ярый иде…» – дип, кешене кимсетмичә генә әйтте. Киңәшләрен исә, кешене үз бүлмәсенә чакырып, күзгә-күз карап кына әйтә торган иде. Хезмәткәр үпкәләп калмасын өчен, аның уңай сыйфатларына басым ясап, мактап, эшкә дәртләндерә белде. Шуңа да аңа беркем үпкәли алмады, киресенчә, рәхмәтләрен генә әйтте.

Шәмси аганың турыдан-туры ярдәмчесе дә булырга туры килде миңа. Шул җәһәттән аның эш кәгазьләрен дә, кульъязмаларын да, китапларын да язу машинасында бастырдым. Аерым алганда, Татарстан китап нәшриятында татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Муса Җәлил – партия солдаты», «Муса Джалиль – солдат партии», «Муса Җәлил, аның каләмдәшләре», «Муса Джалиль – интернационалист» китапларын үз кулымнан үткәрергә һәм бу китапларны язганда кирәк булган һәртөрле эш кәгазьләрен дә, Бөек Ватан сугышы һәм аңа кадәр булган чордагы газета төпләмәләреннән Муса Җәлилнең (ул вакытта латин графикасында) мәкаләләрен, информацияләрен, шигырьләрен хәзерге кириллица хәрефләре белән күчереп язарга да туры килгәләде. Бүләк итеп биргән китапларга: «Ярдәм иткән өчен рәхмәт әйтеп, ихтирам белән Шәмси абыең», – дип язып бирде. Мин ул китапларны бүген дә кадерле ядкәр итеп саклыйм.

Әйтергә кирәк: үзенә ярдәмчеләрне дә сайлый белә иде мөхәррир. Шул җәһәттән Миншәех Зәбировны искә алып китәр идем. Газетаны тәртиптә тотарга ярдәм итүче җаваплы сәркатип Миншәех Харисович миһербанлылыгы, ярдәмчеллеге, оештыра белү сәләте белән бик күпләрдән аерылып торды. Бу чорда редакциядә танылган журналистлар Рафак Тимергалин, Марат Әмирханов, Дифгать Сираев, Мөнир Әһлиуллин, Мөнир Абдуллин, Әхмәт Гаязов, Ислам Әхмәтҗанов, Габделбәр Ризванов, Сәмигулла Хәйретдинов, Әмин Раков, Илдус Илдарханов, Хәлим Гайнуллин һәм башкалар эшләде. Коллективта бер-береңә карата үзара хөрмәт, ярдәмчеллек, игътибарлылык, какшамас тәртип хакимлек итте. Боларның барысы да җитәкчебез Шәмси ага Хамматов абруе белән эшләнде. Үз-үзенә битараф, эленке-салынкы булганнарга аның киңәше бер генә булды: «Коллективка тап төшермәгез, гаиләгезне борчуга салмагыз!» Хезмәткәрнең нәрсәгә сәләтле икәнен фаразлау сәләте бар иде анда. Талантлыларны, көчле рухлыларны югарырак урыннарга урнаштыру ягын кайгыртты. Газета битләрендә бары тик гаделлекне генә чагылдыруны, килгән кешеләрнең гозерләренә аерата игътибарлы булуны, вакытында чара күрүне таләп итте.

Обком бюросы утырышларында кечкенә генә хата өчен дә шелтәләүләрен Шәмси агадан ишетеп белә идек. Шул вакытларда аз гына дулкынланып алганы өчен дә, бераз тавышымны күтәреп сөйләштем, ахры (хәтта тавышын күтәрмәгән очракта да, эчтән борчылганын сизепмедер), дип гафу үтенә иде.

Хезмәткәрнең гозеренә аерата игътибарлы иде ул. Эшкә урнашканда аның гаиләсе, нинди тормышта, фатирда яшәве белән җентекләп кызыксына. Кирәк булса, ярдәм итү чарасына керешә: торак алырга булыша, матди ягыңны да кайгырта, белемеңне күтәрү ягын да карый. Партия мәктәпләренә, курсларга җибәрү эшен дә җайлый иде. Ә ул вакытта белемеңне күтәрмичә торып, бүлек җитәкчесе яисә югары оешмаларга урнашуны күз алдына да китереп булмый иде.

> **Шәмси ХАММАТОВ:**
> Олы булсаң да, кече була бел. Тырышлыкны бер йодрыкка туплаганда, хәл ителмәслек мәсьәләләргә урын калмый. Журналистлык ул – авыр, әмма мактаулы һөнәр.

Шәмси Хәбибуллович эш аты булды. Газетаның баш мөхәррире вазыйфасын башкару белән бергә, Татарстан Журналистлар берлеген дә җитәкләде, Татарстан өлкә комитеты бюросы, Югары Совет президиумы әгъзасы булып та торды. Аңа ярдәм, киңәш сорап, бик күп журналистлар, язучылар, гади кешеләр дә килде. Шәмси аганы үз итеп, язучылар Нури Арслан, Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Зәки Нури, Мәхмүт Хөсәен, Нәби Дәүли, Самат Шакир, Фатих Хөсни кебек каләм ияләре еш булды. Мәхмүт Хөсәен, Нәби Дәүлинең шаярып сөйләшүләре әле дә хәтеремдә.

Тормыш гел эш белән генә бармый, әлбәттә. Шәмси аганың гаиләсе белән дә элемтәдә торып, телефоннан аралашырга туры килде. Фатирларына кунакка да дәшәләр, шундый кунакчыл, үз туганнары кебек кабул итәләр иде. Хатыны Наилә ханым, кызы Дамирә ханым, улы Шамил белән дә элемтәдә тордым. Очрашкан саен ниндидер дулкынлану кичереп, сокланып кала идем бу гаиләгә.

Шәмси аганың биргән киңәшләре, акыллы фикерләре һаман да ярдәм итә, яшәргә дәрт, илһамланырга көч бирә, дисәм дә, хакыйкатькә хилаф итмәмдер. Аның җитәкчелегендә 1983 елның июненә кадәр эшләргә туры килде (ул лаеклы ялга киткәнче). Һәм ул минем өчен чын тормыш мәктәбе булды дип саныйм. Шәмси аганы бүген дә аерата мәрхәмәтле, шәфкатьле, милләтне кайгыртучы олуг зат итеп искә алам.

Бүген татар милләтендә мондый кешеләр күбрәк булсын иде. Шәмси абый бит ул зур океанда боз тауларын ерып барган бозваткыч корабны хәтерләтә. Нинди генә хәлдә дә ул ана телебезне бетерүгә юл куймады. Хәтта генсек Леонид Брежневның «бер совет теле»нә алып барырга яисә яшерен рәвештә халыкларны руслаштыру сәясәтенә дә үзенең какшамас дәлиле белән берләштерелгән өлкә газеталарының төп яисә әйдәүче редакция итеп татар редакциясен калдыртты һәм кырыс вә кискен көрәш барганда телебезне яклый алды.

Бүгенге мөхәррирләргә шундый көч, шундый дәрт, шундый кодрәт телим.

Сәкинә АЛТЫНБАЕВА

# ТАШКА БАСЫЛГАН

**Ислам ӘХМӘТҖАНОВ (1972–1991 елларда корреспондент, өлкән корреспондент, бүлек мөдире, җаваплы секретарь булып эшли):**
Тарих канлымы ул, шанлымы – барыбер халык хәтеренә уела, киртләнә барган һәм бара. Телефон-радио дигәннәренең исеме дә ишетелмәгән, телевидениенең дулкыны да колакка чалынмаган унынчы-егерменче, утызынчы-кырыгынчы елларда әлеге тарих кайда чигелеп, чор-дәвер кардиограммасы кайда язылып калган соң? Аңлашыла ки, беренче нәүбәттә басма сүздә – газетада – «Эш» битләрендә. Газета, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, тарих елъязмасы рәвешендә яшәвен дәвам иттерде, татар халкының киңәшчесенә, булышчысына, таянычына әйләнде. Сүз ул игелек кылыр өчен яратылган. Димәк ки, төп коралы сүз булган «Ватаным Татарстан» киләчәктә дә хакыйкатькә, әхлакка, гүзәллеккә хезмәт итәр. Мөхтәрәм басма киләчәктә дә мөстәкыйльлегебез сагында калыр, газиз милләттәшләребезне республиканың абруен, куәтен, рухи егәрен ишәйтергә туплар.

**Гарәф ШӘРӘФЕТДИНОВ (1951–1955, 1961–1973 елларда корреспондент, Азнакай төбәгеннән үз хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы секретарь, редактор урынбасары булып эшли):**
Газетада эшли башлаган чорда Галим Рябков, Фатих Балыкчы, Гавриил Беляев, Фазыл Мөбарәкшин кебек олпат журналистларның абруйлары сокланырлык югары булды. Хәтта газета тарихында тагын шулай мәшһүрлек казанган берәр чор, ай-һай, булыр микән сыманрак тоела иде. Әмма һәр чорның үз кешеләре, шәхесләре була икән. Алтмышынчы-җитмешенче елларда редакциядә эшләгән каләм ияләрен күз алдыннан үткәреп карыйм: Шәмси Хамматов, Мәрьям Дибаева, Рафак Тимергалин, Флорид Әгъзамов, Шәех Зәбиров, Мөдәррис Мостафин, Нәкыя Вәлиева, Мәҗит Рафиков… Нинди дәрт-илһамият еллары. Нинди үсеш, алга китеш. Сиксәненче-туксанынчы елларның талантлы журналистларын күр инде. Аларның язганнарын су кебек эчәсең, укып туеп булмый. Бу куаныч киләчәккә өмет уята. Әйе, хәзер заманалар башка, олы юл үткән газетабызның укучылар алдындагы бурычы да һаман үсүгә таба бара шул. Шундый тормышта яшибез: берсеннән-берсе җитдирәк мәсьәләләр туып кына тора.

**Мөдәррис МОСТАФИН (1944, 1960–1984 елларда Әлмәт төбәгендә үз хәбәрче, бүлек мөдире булып эшли):**
Безнең буынга халыкның батырлыгы белән данлы, көчле рухлы, шул ук вакытта катлаулы һәм авыр заман туры килде. Тамак ипигә туймаган вакытлар да аз булмады. Газета партиянең каты күзәтүе астында тотылды. Ул күрсәткән юлдан уңга да, сулга да борылырга ярамый иде. Шулай да бөтен авырлыклары һәм шатлыклары белән «Ватаным Татарстан» газетасында эшләгән елларны сагынып һәм горурланып искә алам. Ул элеккечә үк якын, аның бүгенге иҗади уңышлары куандыра.

**Шәех ЗӘБИРОВ (1967–1990 елларда бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары, җаваплы секретарь булып эшли):**
Чирек гасыр гомеремне, яшьлегемне, көчемне, акылымны, дәрт-дәрманымны «Социалистик Татарстан»га багышладым. Газетаның баш мөхәррирләре Шәмси Хамматов белән Рәис Сабиров миңа штаб белән идарә итүне – газетабызның җаваплы сәркатибе булуны ышанып тапшырдылар. Бергә-бергә шәп газета чыгардык, дип әйтә алам. Нәкъ шул чорда республикабыз уңышларын төрле яклап иҗади яктыртып, тарихта беренче тапкыр бөтенсоюз конкурсында җиңеп чыгып, күрше редакцияләрне дә шаккатырып, «борыннарына чиртеп», ВДНХ медальләренә лаек булдык. Татар халкының, татар милләтенең үткәнен дә, киләчәген дә бу газетадан башка күз алдына китереп булмый.

1986 ел. Рәсемдә – «Социалистик Татарстан» газетасы журналистлары Ислам Әхмәтҗанов, Зиннур Мансуров, Хәлим Гайнуллин, Габделбәр Ризванов гаиләләре.

**Хәмит МӨХӘММӘТШИН (1962–1965, 1970–1991 елларда Чаллы төбәгендә үз хәбәрче булып эшли):**
Газета турыдан-туры чынбарлык, тормыш белән очраштырды. Кысаның тарлыгы, эшнең ашыгычлыгы кыска, тиз, аңлаешлы итеп язарга өйрәтте. Мәкалә-хәбәрләребездә КамАЗ төзүчеләренең күмәк һәм шәхси портретларын тудырып, республикабыздагы кайнар төзелеш еллары сулышын сиздереп торганбыз икән, без, журналистлар, Чулман буенда туган батырлык сәхифәләрен язуыбыз белән горурланабыз, төзелештә үз өлешебез булуына шатланабыз.

**Мәрьям ДИБАЕВА (1941 елдан лаеклы ялга киткәнче әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли):**
Минем университетым, мәхәббәтем, бөтен тормышым – «Ватаным Татарстан». Гомер юлымдагы бөтен шатлыкларым һәм кайгыларым, табышларым һәм югалтуларым шушы газета редакциясендә булды. Мин аңа чиксез рәхмәтлемен һәм бурычлымын. Мең яшә, газиз газетам!

# Газета белән янәшә

**Үткән гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында Балтач районында газетабызның ул чактагы исемен йөрткән, республикада гына түгел, ил күләмендә танылган бер колхоз бар иде. Иде дип, ул әле дә, исемен үзгәртсә дә, җисемен үзгәртмичә, гөрләп яши. Шунысы да бар: хуҗалыкның күтәрелеш еллары нәкъ менә безнең исемне кабул иткән чордан башлана.**

– 1972 ел иде, – дип искә алган иде бер очрашуда күп еллар әлеге хуҗалыкта башлангыч партия оешмасы секретаре булып эшләгән Габделхак ага Латыйпов. – Газетаның ул чактагы редакторы Шәмси абый Хамматов безнең районга килгәч, райкомда: «Егетләр, берәр юньлерәк колхозга безнең исемне бирик әле», – дигән. Ә Шәмси абый – ул чакта обком бюросы әгъзасы, дәрәҗәсе бик зур. Аның теләгенә каршы килү түгел, сөенә-сөенә риза булалар. Шулай итеп без «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхозга әйләндек. Менә шуннан безнең бу газета белән чын-чыннан хезмәттәшлек башланды. Без шулкадәр күп аралашып яшәдек, газета журналистлары Балтачка килсә, безгә керми китмәде, без дә, Казанга барсак, редакциягә керми кайтмый идек. Ул елларда газетаның абруе шулкадәр зур, бу коллектив белән аралашу безгә дә дәрәҗә өсти иде. Ә инде Шәмси абый кебек редактор белән дустанә аралашу бик күпләрнең хыялы булса да, ул бик азларга тәти иде. Колхоз ирешкән уңышларны яктыртуда, безнең тәҗрибәне республикада таратуда бу коллектив шулкадәр олы хезмәт куйды: без күп еллар Шәмси абыйны, Мөнир Абдуллин, Мидхәт Шакирҗанов, Габделбәр Ризванов һәм башкаларны зур хөрмәт белән искә алдык. Габделбәр Ризванов исә, безнең колхозның тарихын өйрәнеп, бик күп кызыклы мәгълүматлар туплап, аерым китап чыгарды. Бу әйтеп бетергесез олы хезмәт булды, бик күп тапкыр кайтырга, тау-тау документларны өйрәнергә туры килде аңа. Шуңа күрә ул бездә үз кешегә әйләнгән иде инде. Редакция коллективы белән үткәрелгән очрашулар, актив хәбәрчеләрне бүләкләүләр эзсез калмады. Безнең авыллар гомер-гомергә бу газетаны иң күп яздырып укучы булды. Без дә газета исеменә беркайчан тап төшермәдек: колхозыбыз Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, күп тапкыр ил күләмендәге күчмә байракларга лаек булдык, ул чактагы рәисебез, мәрхүм Харис Галимуллин СССР Верховный Советы депутаты булып сайланды, районда беренче «атказанган» исеме алучы агроном да, механизатор да безнең хуҗалыкта булды… Шөкер, ул чакта яуланган үрләр бүген дә югалмый, колхозыбыз, исемен үзгәртсә дә, элекке матур традицияләр дәвам итә, ул әле дә республика күләмендә мактаулы.

21 ел «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз булып йөргән бу хуҗалык, газетабыз исемен үзгәрткәннән соң, кабат «Татарстан»га әйләнеп кайта. Бер җирлектән күп еллар дәвамында иң актив өч хәбәрчесе булган (Җәмилә Сибагатуллина, Рамазан Фәрзиев, бертуган апам Миләүшә Гарифуллина) җирлектән менә инде унсигез елга якын үзем дә махсус хәбәрче булып эшлим. Бу еллар эчендә хуҗалык җитәкчеләренең иллегә кадәр хезмәт алдынгысын, ветеранын «Ватаным Татарстан» газетасына подписка белән бүләкләгән чаклары булды. Алар һәрчак безнең газетага карата хөрмәтле булды, газета сүзенең көчен дөрес бәяләде. Үзем дә биредәге һәр яңалык, тырыш, уңган авылдашлар, сәләтле яшьләр, үрнәк гаиләләр, язмыш сынавына бирешмичә сокландыра белгән кешеләр, шушы җирлек мисалында авыллар өчен хас күп төрле проблемалар турында язарга тырыштым.

– Район газетасында да чыкмаган күпме авылдашларны республика күләмендә таныттың, күпме эшләребезне яктырттың, – дигән иде элекке укытучым Рауза апа Зиннәтуллина. Бу сүзләрдә дә хаклык зур.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

# МӨХӘРРИРЛӘР

**Хәсән Урманов** – газетаны оештыручы

**Вәли Шәфигуллин** (1918–1921 еллар)


**Фәтхи Бурнаш** (1921–1923 еллар)

**Фатих Сәйфи-Казанлы** (1923–1925 еллар)

**Галимҗан Нигъмәти** (1926–1927 еллар)

**Сафа Борһан** (1928–1929 еллар)

**Исхак Еникиев** (1930, 1931, 1937 еллар)

**Гаяз Ризванов** (1932–1936 еллар)

**Әхмәтсафа Дәүләтьяров** (1937 ел)

**Һади Габдрахманов** (1938–1941 еллар)

**Ибраһим Үзбәков** (1941–1950 еллар)

**Галим Рябков** (1950–1960 еллар)

**Шәмси Хамматов** (1960–1983 еллар)

**Рәис Сабиров** (1983–1990 еллар)


**Мөнир Әһлиуллин** (1990–1996 еллар)

**Габделхак Шәмсетдинов** (1996–2003 еллар)

**Миңназыйм Сәфәров** (2003–2019 еллар)

**Гөлнара Сабирова** (2019 елдан)

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

**«ВТ» – 105** 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

# АЙ, КЫЗЛАР!

Анна Арахамия

## Тарихның бер мизгеле

**Бу дөньяда миннән бәхетле кеше юктыр. Өч иҗтимагый формациядә яшәп кара әле син! Социализмда тормыш гөрләп барды, капитализмга охшаш җәмгыятьнең түмен дә татыдым. Инде менә матриархат чорында яшим.**

«Ватаным Татарстан» газетасында бүген, нигездә, кызлар гына эшли. Мин журналистларны күз алдында тотам инде. Ирләр өммәтеннән, техник хезмәткәрләрне санамаганда, каләм ияләре өчәү генә калдык. Иң өлкәне – мин, миннән бераз гына кече – Габделбәр Ризванов һәм урта яшьләрдәге егет, егет дип, бераз тотылган кәнишне, Илнар Хөснуллин. Илнар – баш мөхәррирнең беренче урынбасары, шуңа шатланабыз да әле, ул-бу була калса, яклау табарбыз дип өметләнәбез. Ир затыннан штаттан тыш хәбәрчеләребез Рәшит Фәтхрахманов, Наил Шәрифуллин һәм Марат Кәбиров бар үзе, тик алар көн дә редакциягә йөрми шул…

Матриархат чорына әкрен-әкрен кердек без. Формация алмашыну баш мөхәррир булып Миңназыйм Сәфәров эшләгәндә үк башланды. Үзе университетның журналистика факультетында укыта да иде Миңназыйм һәм укырга килүчеләр арасында егетләрнең кимү баруы турында йөрәге әрнеп сөйли иде.

Шушы арада гына хәбәрләшеп алдык, хатыннарыбызны бәйрәм белән котлаштык. Мин аңа «Ватаным Татарстан»ның матриархат чорына ныклап аяк басуы турында әйттем. Бер дә шаккатмады Миңназыйм, алай гына да түгел: «Әле менә үзебезнең кызларны сигезенче март белән котладык, 13 кыз арасында Фәннүр Хәсәнов белән икәү генә утырдык», – диде. Ул Дәүләт телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар бүлеген җитәкли, «көчле» затларның күп өлкәдә гүзәл затларга бирешә башлавы аны да бик уйландыра. «Син беләсең микән, Риман абый, хәзер хезмәт базарында зур үзгәрешләр бара, ирләр хатын-кыз һөнәрләрен үзләштерә башлады бит», – ди.

> Без үсмер чакта журналист һөнәре нигездә ир-атныкы саналды. Мин җиденче класста укыганда бугай, авылда: «Казаннан корреспондент килгән», – дигән хәбәр таралды. Әле авыл кешеләренең шаккатып: «Үзе хатын-кыз икән», – дип пышылдашуы да истә калган. Бүген авылга журналист килсә, мөгаен: «Үзе ир кеше икән...» – дип шаккатып сөйләрләр.

Хәзер газетабызның баш мөхәррире – Гөлнара Ильяс кызы Сабирова. 105 еллык тарихыбызда җитәкчелеккә хатын-кыз килүе – беренче очрак. Яшерен-батырын түгел, Миңназыйм Сәфәров урынына хатын-кыз килә икән дигән хәбәр чыккач, бу кайберәүләр өчен гайре табигый тоелды. Япь-яшь кыз бала шундый абруйлы басма, хөкүмәт газетасы эшен ничек алып бара алсын ди?! Әлбәттә, икеләнүләр, шикләнүләр бик тиз юкка чыкты. Чөнки Гөлнарабыз – үз кеше, журналист хезмәтенең никадәр авыр һәм җаваплы, никадәр мактаулы һәм кызыклы икәнен үзе татыган кыз иде.

«Гөлнарабыз» дип әйтергә минем тулы хакым бар дип уйлыйм. Аның иҗат юлы мин баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән «Татарстан яшьләре» газетасында башланып китте. Без үзебезне Исмәгыйль Шәрәфиевнең шәкертләре дип саныйбыз. Гөлнара өчен Миңназыйм Сәфәров та – остаз. «Ватаным Татарстан» нәкъ менә Миңназыйм килгәч зур үзгәрешләр кичерә башлады, халык яратып укый торган газетага әйләнде.

Дөресен әйткәндә, газета битләрендә үз мөхәрриреңне мактау килешми инде ул, бераз ялагайлануга тартым була кебек. Шул ук вакытта Гөлнарабыз турында әйтмичә дә булдыра алмыйм. Эчендәге тышында аның. Газетага һәрвакыт ниндидер яңалык кертергә омтылыр, ни эшләргә икән, дип аптырап торуын хәтерләмим. Кайбер җитәкчеләр үзләрен раслар өчен вак-төяккә бәйләнергә яраталар, эш югында эш табалар. Ә минем, бер бинада, бер катта булып та, Гөлнараны көннәр буе күрмәгән чакларым була, чөнки юкка-барга борчымый ул безне. Кайчак, аптырагач, бүлмә ишеген ачып, башымны тыгам да: «Только поздороваться», – дип елмайган булам.

«ВТ»ның матриархат чорына аяк басуын яздым инде. Кайчак Гөлнара үзе дә: «Их, йөгереп йөреп эшләр өчен редакциядә хет бер-ике яшь егет тә булса…» – дип әйткәли. Тик юк алар… Бүген дөньясы әллә кайсы якка үзгәрде. Кайбер дәүләтләрнең Президентлары, Премьер-министрлары, гомумән алганда, җитәкчеләр, сәясәтчеләр – хатын-кызлар. Рәсми саннарга карасаң, бүген Европаның 7 дәүләтен хатын-кыз җитәкли. Азия, Көньяк Америка, Африка илләрен дә кертсәк, алар җәмгысы 17гә җыела икән һәм саннар кимүгә бармый. Дөньяда 151 дәүләт барлыгын әйтсәк, бу бит уртача һәр 11 дәүләтнең берсе гүзәл затлар кулында дигән сүз. Моңа 193 хөкүмәтнең 19ын хатын-кызлар җитәкләвен дә өстәсәк, матриархатның бөтен дөньяда яңадан-яңа үрләр яулавын күрербез.

> Галимнәр әйтүенчә, чиста матриархат җәмгыятьләр тарихта булмаган, әмма, мәсәлән, Һиндстан, Нигерия, Непал, Тибет җирләрендә яшәүче кайбер халыклар белән һаман да хатын-кыз җитәкчелек итә икән. Андый халыкларда милек хатын-кыз буыны аша күчә, балалар әниләре фамилиясен ала, дип ишеткәнем бар. Ирләр, мескеннәр, хатын-кызлар белән бертигез хокук алу өчен көрәш алып баралар, ди. Шуларны уйлыйм да, «ВТ»дагы матриархат – иң кешелеклесе, дим.

Мин еш кына вестибюльгә чыгып, кәнәфигә утырам да, мәш килеп, арлы-бирле йөгергән гүзәл кызларыбызны күзәтәм. Аларга заманның авыр йөген тартырга туры килә. Бүгенге буталчык чорда кызларыбыз газета аша дәүләт сәясәтен алып барырга мәҗбүр. Алар бүгенге идеологияне дөрес аңларга һәм халыкка дөрес итеп җиткерергә тиеш.

Каян барысына да җитешә кызларыбыз?! Йөгереп чыгып китәләр, йөгереп кайталар да шундук язарга утыралар. Кайбер кызларыбызның инде икешәр, өчәр оныгы да бар, аларга да вакыт табалар, ирләрен дә көйлисе бар. Юк, без – ирләр, алар кебек эшли алмыйбыз. Кайчак, хатын-кызга сыенып, аңа ышыкланып яшибез кебек тоелып китә.

Кайдадыр укыганым бар: хатын-кыз җитәкләгән оешмада акча-макча яклары тотрыклырак була икән. Аннан соң, тыштан салкын күренгән җитәкче хатын-кызның күңелендә хисләр өермәсе уйный, ди. Моны укыгач, Гөлнарабызның шагыйрә булуын да уйлап куйдым. Инде килеп, хатын-кыз ир җитәкче кебек вак-төяккә бәйләнми, кул астындагылар белән бик дустанә мөнәсәбәттә була, кешенең хәленә керә, эшен күрә – бәяли белә ди. Карале, бу сыйфатлар безнең мөхәрриргә тач килә дә тора икән.

Шушы яшемә җитеп һаман да эшләп йөрүем, бәлки, нәкъ менә гүзәл затларга тартылуыма да бәйледер. «ВТ»да ирләр өмметеннән журналистларның бетә баруына көенсәм, кызларымны күз алдына китереп сөенеп куям. Өлкәнрәкләрен дусларча кочакларга теләсәм: «Риман абый, кагылма, картлыгың йога», – дип шаяртып күңелне күтәрәләр. Ә яшьләрдә мин киләчәк тормышны күргәндәй булам. Өметле, якты, матур булып күренә ул миңа. Кызларыма яңа исемнәр дә тагып бетердем. «Таң йолдызым» – Чулпан Гарифуллина. Динә Гыйлаҗиева белән Эльвира Вәлиевага «кояшым» дип дәшәм. Шулай итеп, күктәгесе белән бергә өч кояшым бар булып чыга. Лилия Гыймазова – «чәчәгем», Ләйсән Сафина – «мадонна». Ләйсәннең елмаюы мәшһүр рәссам Рафаэль Санти ясаган мадонналарның серле күз карашын хәтерләтә. «Газиз киленем» – укытучым Илсум абыйның оныгының хатыны – Зөһрә Садыйкова, Сәрия Мифтахова – «Гөлсәрия», «кызым» – Гөлгенә Әүхәдиева, «якты баш» – Зөлфия Хәлиуллина. Үзем кушкан исем белән дәшкәнгә үпкәләми алар, «әү» дип кенә торалар. Алар белән күңелле, рәхәт миңа. Эшкә килүгә: «Нихәл, Риман дәдәй», – дип урынбасар Гөлинә Гыймадова каршы алыр. «Кофе ясап бирер идем дә, сөт юк икән, сөтсез кофе организмдагы кальцийны юа икән. Ә без синең сәламәт булуыңны телибез», – дип төрттерер. Бүлмәдәшләрем «Фәниюшка» (Фәния Әхмәтҗанова), «Терешкова» (Валентина Семенова), «Исмәгыйлевна» (Фәнисә Хәйретдинова) белән бер гаилә булып яшибез. Фәнияләрнең икенчесенә – корректор «Фаечка»га (Фәизова) да «Привет!» димичә узмыйм. Күрше бүлмә кызлары «Гуленька» (Гөлнара Зиннәтуллина) белән «Лили» (Лиана Мәрданова) мин керүгә хәл сораша башлыйлар. Кызларыбызның тагын берсе – Гөлгенә Шиһапова кешегә ярдәм итәр өчен яралган зат. Мин аңа «Тиктормасым» дип дәшәм.

«ВТ»дагы биш кызның исеме «Гөл…» дип башлануы очраклы хәл түгел, кызлар безнең мәңге шиңмәс тормыш гөлләребез. Һәрхәлдә, шулай булсын иде! Алтынчы «Гөл…»ебез дә бар әле. Ул – Балтачта яшәүче хәбәрчебез Гөлсинә Хәбибуллина. Аерым торсак та, мин аны һәрчак үзебезнең арада итеп тоям.

Мин «кызлар» дип язам язуын, әмма кайберләренең, ирләрен дә кертеп, өчәр-дүртәр баласы бар. Ике «Илюска»ның икесе дә (Илүсә Сөнгатова, Илүсә Минһаҗева) бертуган сеңелләрем кебек. Актаныш кызы «Раечка» (Рәзинә Сәлахиева) янышнан: «Актаныш кызлары белән ах… таныш булулары», – дип җырлап узам. Кассир-бухгалтер «Светик» (Светлана Афонина) мине күргән саен: «Почему я тебя так люблю, Риман абый?» – дип гаҗәпләнә. Ә мин аңа: «Мы оба очень хорошие люди», – дим. Баш бухгалтер Илсөяр Вәлиуллина белән киңәш-табыш итеп яшим.

Еллар узар, кешеләр татар матбугаты тарихына әледән-әле күз салырлар һәм фәләненче гасырның фәләненче елларында татарның олпат басмасын гүзәл затлар чыгарган икән, дип сокланып куярлар. «Кызлар чоры» газетабызның матур бер сәхифәсе булып тарихка кереп калыр. Ә бүген без, «ВТ»дагы берничә бөртек ир, бәйрәм саен композитор Әнвәр Бакировның Риза Ишморат сүзләренә язган «Ай, кызлар, йолдызлар» дигән җырын җырлыйбыз. Ул безнең гимн кебек.

*Сызылып киткән эз калдыра,*
*Алар нинди йолдызлар?*
*Эз калдырып үтә шулай*
*Яшь кызлар, чибәр кызлар…* –

дип бары тик безнең сылуларга җырларлык дип уйлыйм. Тик менә ирләр калмаса, аларга багышлап кем җырлар җырлар икән дип моңсуланып та куям.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

**Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 5332 данә**
**Гомуми тираж – 15281 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 234

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+